Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 50 (1466) 22 декабрь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

12-13

Бер ай чамасы элек кенә Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Наилә Гәрәеваны югалтсак та, ул һәр көн, һәр сәгатьтә безнең күңелләрдә яши, аны юксынабыз.



16-17

Төньяк Уралдагы Искор шәһәрчеген 1472 елда баскыннар үзләре ут төртеп яндырган, халкын кылычтан үткәргән, әмма аңа кадәр мәҗүси булган Параскеваны ни өчендер изгеләштереп, аның хөрмәтенә часовня да куйганнар әле.

18

Безнең Алсу мөлаем, сөйкемле, эчкерсез генә түгел, ул бик укымышлы, югары зәвыклы, һәркемгә ярдәм кулын сузарга әзер булган зур терәк тә әле.

Куенына алып җылыт, аклык, – Күшекмәсен илдә тиен дә!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Россия Президенты карары нигезендә ташламалы ипотека буенча кертем 30 процентка кадәр артты.
- «Казан» гаилә үзәге янындагы Яңа ел чыршысында иллюминация кабынды.
- Түбән Каманың Т.Миңнуллин исемендәге Татар Дәүләт драма театры Ркаил Зәйдулла пьесасы буенча куелган «Нәгыймә» спектаклен Казан тамашачысына тәкъдим итте.
- К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында XXV#ӘдәбиМарафонның финалистларын бүләкләү тантанасы үтте.
- Уфада Әхмәтзәки Вәлиди исемендәге Милли китапханәдә Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллинга багышланган «Курай булып кайтырмын...» истәлек кичәсе узды.
- Казан вәкилләре Санкт-Петербургта узган «Россия тәрбиячеләре» конкурсында призлы урыннар яулады.
- КФУның Г.Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбендә профессор, галим Марсель Бакировның 90 еллык юбилеена багышланган «Остаз, галим» дигән чара узды.
- Казан Ратушасында шәһәр мэры Илсур Метшин буыннар дәвамында табиб эшенә тугрылык саклана торган гаиләләрне котлады.
- Татарстанның «Казанькомпрессормаш» АҖ, «Промтех-Казань» АҖ һәм «НПК «Аэрокон» ҖЧҖ компанияләре АКШның Россиягә каршы чикләү чаралары исемлегенә кертелде.
- Казан аэропортыннан Мисырның Шарм-эш-Шәех һәм Хургада шәһәрләренә авиарейслар җибәрелде.
- Казанның «Салават Күпере» торак районында Чыршы шәһәрчеге ачылды.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

23 декабрь – рәссам, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык рәссамы Евгений Владимирович Зуевның тууына 100 ел (1923-1989);

– этнограф, Татарстан Республикасының Дәүләт бүләге лауреаты Рәмзия Гыйнният кызы Мөхәммәдованың тууына 100 ел (1923–2020).

25 декабрь – актриса, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Фатыйма Хәйрулла кызы Камалова (Хәлиуллина)ның тууына 120 ел (1903-1974).

26 декабрь – язучы, хәрби һәм сәяси эшлекле Шамил Хәйрулла улы Усмановның тууына 125 ел (1898-1937).

28 декабрь – театр белгече, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Хәсән Хәйрулла улы Гобәйдуллинның тууына 110 ел (1913-1992).

СЫНАМЫШЛАР

25 декабрьдә агачларга бәс сарса, алдагы елда иген уңар ● 25 декабрьдә иртән тын булып, йомшак кына кар яуса, ашлык уңар; әгәр кар көндез яуса, чикләвек күп булыр; җылы һәм буранлы булса, җәй салкын килер ● 25-27 декабрьдә тамчы тамса, 29 июньдә кырау төшәр; кыяр, тары уңмас, карабодайга килешер.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **8 сәгать 13 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 12 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **6 сәгать 59 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **3 минутка** озынаячак һәм киләсе җомгада, ягъни **29 декабрьдә 7 сәгать 02 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Декабрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 22, 23 декабрь.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(19-27 декабрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген җөмәдел ахир аеның 9 нчы көне

ҖАН АВАЗЫ



Марс ГАИТОВ, Татарстанның атказанган икътисадчысы

МӘҢГЕЛЕК Илһам Шакиров

Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов фәрманы белән 2023 ел – Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителгән иде. Бу карарны хуплап каршы алдык. Аны бер өлешен тормышка ашыру өчен мәктәп елларыннан (1952-1953) бирле гомерлек дустым булган Илһам Шакировка багышлап язылган «Бөек җырчы дустым» исемле мәкаләм «Мәдәни җомга» газетасында 2023 елның 10, 17, 22 февраль саннарында басылып чыкты.

Апрель аенда интернетның Ютуб сәхифәсендә «Илһам Шакиров турында истәлекләр» исемле канал ачтым. Биш тапшыру вакытында Илһамның биографиясе һәм иҗаты, гыйбрәтле хәлләр турында сөйләдем, хатирәләрем белән уртаклаштым. Бу тапшыруларны 3 меңгә якын тамашачы карады. Хәтта ерак Красноярск шәһәреннән килгән комментарийлар да Илһамның тыңдәшсез җырлары онытылмавын, милләттәшләребез күңелендә мәңге яшәвен раслый.

1995 елда җырчыбызның 60 еллык юбилеена багышлап «Илһам» исемле сувенир-китап дөнья күргән иде. Әлеге җыентык өчен, беренче чиратта, халык шагыйре Разил Вәлиевка рәхмәтлебез. Тарихи басманың кереш сүзендә Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин: «Илһам кебек талантыбыз булу барчабыз өчен дә горурлык ул», – дип язган. Китапта мәшһүр сәнгать ияләре Н.Исәнбәт, С.Хәким, Г.Ахунов, Т.Миңнуллин, Р.Батулла, Г.Рәхим бөек Илһамны Г.Тукай һәм С.Сәйдәшев дәрәҗәсендәге олуг сәнгатькәр дип бәя биргән. Җыр шигырьләре остасы Гөлшат Зәйнашеваның да:

Җыры белән илне нурлады ул,
Туган халкыбызны зурлады! –

дигән сүзләре бар.

И.Шакировка мәшһүр музыкантлар Латыйф Хәмиди, Фоат Мансуров, Нәҗип Җиһанов, Натан Рахлин, Мстислав Растропович; шөһрәтле җырчылар Фәридә Кудашева, Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Әлфия Авзалова, Салават Фәтхетдинов һ.б.; әзәрбайҗан җырчысы Мөслим Магомаев, казакъның Бибигөл Түләганова һ.б. югары бәя бирде. Илһамга булган мәхәббәт аңа Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясен, РФ, Татарстан һәм Каракалпак республикаларының халык артисты исемен бирүдә, Бөтенроссия «Алтын Аполлон» бүләге, Халыклар дуслыгы, Почет, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары белән бүләкләүдә дә чагылды.

Илһамны татар халкы язмышы гомер буе борчыды, халкым бәхетле булса гына, мин бәхетле була алам, дия иде. Ул дөньяның төрле кыйтгаларына, зур илебезнең күп төбәкләренә таралган татар халкын бербөтен милләт итеп берләштерү өчен күп көч куйды. Гастрольләре вакытында СССРның 32 зур шәһәрләрдә концерт бирде. Чын каһарман булып, кайчак сәхнәдә 20-30 җыр башкарды. Читтәге милләттәшләрне Туган җиргә кайтырга өндәде. Аның киңәше буенча, меңнәрләгән татарлар Татарстанга кайтып, КамАЗ, Алабуга, Түбән Камада зур төзелешләрдә эшләде, шул төбәкләрдә төпләнеп калды.

Илһам Шакировның якты исемен мәңгеләштерү максатында Татарстан хөкүмәте күпьяклы программаны тормышка ашырды. Туган авылы Яңа Бүләктә (Тукай районы) ике катлы мәһабәт бина төзелде һәм анда 2001 елда «Илһам Шакиров иҗат йорты» ачылды, 2002 елда бинаның икенче катында Илһам музее эшли башлады. 2022-2023 елларда бинага капиталь ремонт ясалды. Яңадан ачылган музей ике катына да экспозицияләр куеп, күркәм эшчәнлеген җанландырды. Музей каршында И.Шакиров бюсты бар, бирегә килгән кешеләр аны сокланып карый. Яңа Бүләк авылы янында чылтырап агучы чишмә 2013 елда төзекләндерелде, аңа «Илһам чишмәсе» дигән күркәм исем бирелде. Авылның Мәдәният йортында ел саен И.Шакиров туган көндә үзешчәннәр концерты шаулап уза, җырларның кайберләрен Илһамның туганнары да башкара. Тукай районы хакимияте ел саен Илһам Шакиров истәлегенә яшь талантлар бәйге дә үткәрә.

Сарманда да яңа урам һәм балалар сәнгать мәктәбе Илһам Шакиров исемендә, аның каршына да җырчының бюсты куелган. Чаллы-Сарман юлының Яңа Бүләк авылына борылышында «Илһам Шакиров туган авыл» дигән язулы, бөек җырчының барельефы бизәгән мемориаль стела бар.

Татарстанның, Сарман, Тукай районнарының энциклопедияләрендә Илһам Шакиров турында мәкаләләр урнаштырылган. 2017 елда «Илһамлы Сарман» исемле китап нәшер ителде (Казан; Яз, – 352 б.; төзүчесе һәм мөхәррире язучы, тарихчы Дамир Гарифуллин). Җыентыкта сәнгать өлкәсендә танылган төбәк шәхесләре һәм Илһам Шакиров турында язмалар бирелгән. Д.Гарифуллин архивлар аша Илһамның сигез буын бабаларын ачыклады һәм шәҗәрәсен төзеде. Җырчы – Сарманның мактаулылы гражданы. Бирема дә «Илһам чишмәсе» исемле төбәкара җыр бәйгесе үткәрелә.

Илһам Шакировның җыр сәнгатендәге казанышларын югары бәяләп, Казан шәһәренең Бауман урамындагы «Йолдызлар аллеясы»нда 2003 нче елда И.Шакиров һәм Ә.Авзалова исемнәре язылган гранит плитәләр урнаштырылды. Казанда яңа урамга Илһам Шакиров исеме бирелде; «Казань-Экспо» үзәгенең 3 мең урынлы зур концерт залы 2019 елда аның исеме белән аталды. Җырчы яшәгән йорт диварына мемориаль такта эленде, кабе-ренә бик матур истәлек ташы куелды. Казан шәһәренең Мәскәү районындагы 32 нче Татар балалар музыка мәктәбе аның исемендә. И.Шакиров – Казанның да мактаулы гражданы.

2019 елда Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов карары белән, 2008 елдан бирле үткәрелеп килүче «Татар моңы» Халыкара яшь башкаручылар телевизион конкурсына Илһам Шакиров исеме бирелде. 2020 елда Министрлар Кабинеты карары белән, И. Шакиров исемендәге Республика премиясе гамәлгә куелды. Аны ике елга бер мәртәбә бирергә ниятлиләр. Әлеге бүләккә Резидә Галимова белән Филүс Каһиров, шулай ук Илһамның энесе, үзешчән җырчы Флүр Шакиров лаек булды инде. 2023 елда бу бәйгедә күренекле җырчылар Флюра Сөләйманова, Фердинанд Сәлахов, Әсхәт Хисмәтов, Фәүдәт Гыйләҗев (Башкортстаннан) җиңеп чыкты.

Илһам иҗатына багышлап «Җырчы» исемле беренче китапны тарихчы, язучы Равиль Фәхретдинов язып, 1973 елда бастырып чыгарган иде. 1995 елда «Илһам» исемле җыентык, 2005, 2010, 2015 елларда җырчыбызның юбилейлары уңаеннан фоторәсемле альбом-китаплар нәшер ителде. Бу басмаларны әзерләүдә халык шагыйрьләре Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим, рәссам Фәйзерахман Камал күп хезмәт куйды.

Шулай да, Рөстәм Миңнехановның киң җәмәгатьчелек алдында игълан иткән: «Без Илһам Шакиров исемен мәңгеләштерергә бурычлы» дигән девизны җиренә җиткереп башкарып чыгу өчен әле алда да мөһим эшләр көтә. Шулардан беренчесе – Илһам Шакировка Казанда һәйкәл кую! Аллага шөкер, мәркәздә Г.Тукай, С.Сәйдәшев һәйкәлләре басып тора. Шулар тирәсендә И.Шакиров һәйкәле дә булса, олуг затларыбызның күркәм ансамбле тулыланыр иде. Илһамның тууына 90 ел тулырга нибары ел ярым вакыт калды. Ә аның һәйкәлен булдыру максатында әле конкурс та игълан ителмәгән. Илһамга Мәскәү каласында һәйкәл калкыту да – бик урынлы.

Казанда Г.Тукай, С.Сәйдәшев музейлары актив эшли, аларга халкыбыз сукмагы өзелми, туристлар да кереп кызыксынып карый. Бөек җырчыбыз Илһам Шакиров та шундый музейга лаек зат!

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институты 2017 елда ике томлы «Г.Тукай» энциклопедиясен нәшер итте. Татар энциклопедиясе институты рус телендә «Салих Сайдашев. Жизненный и творческий путь» исемле монография – академик китап язып бастырды. Ә Илһам Шакиров турында энциклопедия яки академик басма кайчан туар икән? Татарстан язучылар берлеге мәртәбәле оешма санала. Күренекле язучылар безнең Илһам турында әдәби роман, повесть язып та татар халкын шатландырса икән!

«Сез белмәгән Атнабай»

Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шурасы рәисе Васил Шәйхразиев Башкортстан Республикасына эш сәфәренә барды. Биредә ул Россиянең югары мөфтие, Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать хәзрәт Таҗетдин белән очрашты. Бу хакта Бөтендөнья татар конгрессының матбугат хезмәте хәбәр итә.

Очрашуда Васил Шәйхразиев Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган чараларга һәм Бөтендөнья татар конгрессы эшчәнлегенә йомгак ясады. Шулай ук Милли шура рәисе Диния нәзарәтенең Курган өлкәсе Йолдыз авылын торгызуда зур өлеш кертүен билгеләп үтте.

2024 ел Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан «Шәхес елы» дип игълан ителде. Шул уңайдан 11 декабрьдә «Нур» татар драма театрында Башкортстан Республикасының халык шагыйре Әнгам Атнабай иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә булып узды. В.Шәйхразиев Тәлгать хәзрәткә «Сез белмәгән Атнабай» китабын бүләк итте. Очрашуда шулай ук Бөтенроссия татар дин әһелләре җыены турында да фикер алыштылар. Ул 2024 елның маенда Казанда була, чара кысаларында «Болгар җыены» узачак.

tatar-inform.

Люция апа хаты

Без газетабызның 20 октябрь санында куш битебезне Муса Җәлилнең өлкән кызы – Зәкия Садыйковадан туган Люция апаны әтисенең туган туфрагы булган Оренбург өлкәсенә, андагы Шарлык районының Мостафа авылына сәяхәт кылдыруыбызга багышлаган идек инде. 87 ел буе Җәлил Ватанын күрмәгән аның газиз кызына әтисе туган төбәкне манзара кылдыра алуыбыз өчен әллә ничә көннәр буе күңел сөенеп йөрде, оренбурглылар да андый көтелмәгән кунакны бик куанып каршылаган иде. Мусаның яшьлек истәлекләрен тагын да күбрәк беләсе килүдән күңел үрсәләнде, Люция апа белән янә бер кат булса да очрашуны өмет итеп йөрдек.

Һәм, менә, көтмәгәндә, Люция ападан кош теледәй хат килеп төште.

«Хөрмәтле һәм булдыклы татар егетләре! Сезгә зур рәхмәтемне җиткерәсем килә. Салкыннар җиткәч, сез бүләк итеп калдырган ап-ак, җылы шәлегезне бөркәндем: үземне якын иткән дусларым кочагына чумган кебек булдым. Зур эш эшләдегез, егетләр. Әтиемне хөрмәт итеп, үземне якын итеп, әтиемнең туган җирләренә алып кайттыгыз. Әтием йөргән сукмаклардан, басмалардан йөреп, әбиемнең каберен күреп, ятимлегемне онытттым, үземне бәхетле сиздем. Бик зур бурычымны үтәргә ярдәм иттегез, татарлыгымны искә төшердегез. Матбугатта чыккан язмаларыгызны да яратып укыдым, зур рәхмәтләр Сезгә! Сезне сагынып, Люция апагыз».

Без бик мәмнүн, күңелебез яңа очрашулар көтә, Сезне бик сагынабыз.

Ләбиб ЛЕРОН,
Рөстәм ГАЛИУЛЛИН,
Вахит ИМАМОВ.

Үзгәртү мөмкинлеге бар

Быел пенсия тупламаларын башка фондка күчерү турында гариза биргән татарстанлылар декабрь ахырына кадәр фикерләрен үзгәртә һәм әлеге карарларыннан баш тарта алалар. Бу хакта Россия Социаль Фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсенең матбугат хезмәте хәбәр итә. Моның өчен Россия Социаль фондына(СФР) иминиятләштерүчене алмаштырудан баш тарту турында хәбәрнамә тапшырырга кирәк. Документ фондның клиент хезмәтләрендә һәм дәүләт хезмәтләре порталында кабул ителә.

Хәбәрнамә пенсия тупланмаларын Россия Социаль фондыннан дәүләтнеке булмаган пенсия фондына, бер дәүләтнеке булмаган фондтан икенче дәүләтнеке булмаган фондка яисә дәүләтнеке булмаган фондтан социаль фондка күчерүне гамәлдән чыгарырга мөмкинлек бирә.

Пенсия тупланмалары белән кем идарә итүен һәм фондны алыштыру турында гариза бирелгәнме икәнен Дәүләт хезмәтләре порталындагы шәхси кабинетта яки Социаль фондның клиентлар белән эшләү офисларында белергә мөмкин.

Социаль фонд пенсия тупланмаларын вакытыннан алда күчерергә карар кылган барлык татарстанлыларны инвестиция керемен югалту куркынычы барлыгы турында кисәтте. Тупланмалар бер фондта 5 елдан кимрәк сакланган һәм шул вакыт узганчы башка фондка күчерелгән очракта закон нигезендә инвестиция керемнәре тотып калына.

Мәктәпләргә – татар язучылары исеме

Татарстан язучылар берлеге рәисе, халык язучысы Ркаил Зәйдулла республикадагы дистәләгән татар гимназияләренә татар язучылары исемнәрен бирергә иде дигән тәкъдим белән чыкты.

«Бездә бик күп татар мәктәпләре бар. Аларның һәрберсенә атаклы татар язучыларының исемен бирсәк һәм шунда кечкенә генә музеен булдырсак, иҗатын пропагандаласак, минемчә, бу патриотизмга әйбәт өлешебез булыр иде», диде Татарстан язучылары лидеры Ркаил Зәйдулла Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советының патриотик тәрбия темасына багышланган утырышында.

«Әкият»тә – хәйрия чыршысы

«Әкият» курчак театрында балалар өчен бу елның беренче хәйрия чыршысы узды. Бәйрәм ТР Дәүләт Советының «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе әгъзалары тәкъдиме белән һәм алар катнашында оештырылды.

Традиция буенча, нәкъ менә депутатлар Татарстанда яңа ел бәйрәмнәрендә балалар өчен хәйрия чаралары ачалар. Быел театральләштерелгән тамашага махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләреннән, ишле гаиләләрдән булган, шулай ук сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар чакырылган иде.

«Мәрхәмәт–Милосердие» парламент берләшмәсе исеменнән балаларны һәм аларның ата-аналарын яңа ел бәйрәмнәре белән берләшмә җитәкчесе, ТР Дәүләт Советы депутаты Алсу Нәбиева котлады. «Без сезне бу залда сәламләүгә бик шатбыз, бүген без балалар өчен хәйрия чаралары ачабыз, – дип билгеләп үтте Алсу Нәбиева, тамашачыларны сәламләп. – Мондый чараларны үткәрү безнең парламент берләшмәсенең яхшы традициясенә әверелде. Без мөмкин кадәр күбрәк балага үз игътибарыбызны бирергә телибез».

Яңа ел тамашасына бүген 150гә якын бала чакырылган иде. Балаларга рус халык әкиятенә нигезләнгән «Морозко» спектаклен күрсәттеләр. Курчак театры фойесында кечкенә тамашачыларны әкият персонажлары, Кыш Бабай һәм Кар кызы көтеп торды.

Тамаша тәмамлангач, барлык балалар да татлы бүләкләр алдылар.

Хәйрия чыршысында катнашучыларны киләсе Яңа ел белән Дәүләт Советы депутатлары Светлана Вострикова, Елена Кузьмичева һәм Ольга Воронова котлады.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Матбугат хезмәте

Петербургта Җәлил мәктәбе

Санкт-Петербургта, Ватан Геройлары көнен бәйрәм итү кысаларында, шәһәрнең Калинин районында урнашкан 146 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбенә Советлар Союзы Герое Муса Җәлил исемен бирү уңаеннан тантаналы чара булды. Әлеге карарны Санкт-Петербург Топонимика комиссиясе 2023 елның 4 октябрендә раслаган. Мәктәпкә М.Җәлил исемен бирү башлангычы белән Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәре һәм Ленинград өлкәсендәге Даими вәкиллеге, Санкт-Петербург Татар милли-мәдәни автономиясе, мәктәп җитәкчелеге һәм шәһәрнең татар җәмәгатьчелеге чыккан.

Әлеге мәктәптә инде күп еллар дәвамында яшь буынга патриотик тәрбия бирү кысаларында, шул исәптән М.Җәлилнең тормыш юлын һәм иҗади мирасын өйрәнү буенча зур эш алып барыла. Мәктәп укучылары Татарстан Республикасының Даими вәкиллеге тарафыннан үткәрелә торган чараларда һәм «Җәлил укулары» Халыкара сәнгатьле укучылар бәйгесендә актив катнаша. 2020 елда әлеге мәктәп базасында Муса Җәлилнең Хәтер почмагы ачылды.

tatar-inform.

Җиргәндә «Дәрдмәнд укулары»

Башкортстанның Мәләвез районындагы Җиргән авылы мәдәният йортында Дәрдмәндкә багышланган «Дәрдмәнд укулары» төбәкара республика укучылары конкурсы җиңүчеләренең гала-концерты үтте. Бу турыда Мәчетле районы татар милли-мәдәни автономиясе социаль челтәрләрдә хәбәр итте.

«Иҗаты сүнмәс нур булып балкыган, якташыбыз, күренекле татар шагыйребез Закир Рәмиев – Дәрдмәнд», диелә әлеге хәбәрдә.

Мәчетле районының Пугачев гаскәренә атаклы бригадир-генерал Бәхтияр Канкаевны үстереп биргән Олы Ака авылыннан 9 сыйныф укучылары Ирина Гыйльманова һәм Флида Хәмидуллина лауреат исеменә лаек булды. Шигърият сөючеләрне татар теле һәм әдәбиты укытучысы Альбина Нуриева әзерләде. Алар Дәрдмәнднең шигырьләрен татар телендә сөйләде.

Бәйгегә 131 эш кабул ителде. Югары тәҗрибәле жюри әгъзалары алар арасыннан иң көчлеләрне сайлап алды.

1 нче биттә – Табигать гүзәллеге. М.Сәгыйдуллина фотосы.

Россиянең иң яхшы наширлек проекты

ЛАУРЕАТ
ВСЕРОССИЙСКОЙ ОБЩЕСТВЕННОЙ ПРЕМИИ ЗА СОХРАНЕНИЕ ЯЗЫКОВОГО МНОГООБРАЗИЯ «КЛЮЧЕВОЕ СЛОВО» 2023
в номинации «Лучший издательский проект» -
ПРОЕКТ: СЕРИЯ ХУДОЖЕСТВЕННО-АНИМАЦИОННЫХ ИЗДАНИЙ ПО МОТИВАМ РУССКИХ, ТАТАРСКИХ, МАРИЙСКИХ, ЧУВАШСКИХ, УДМУРТСКИХ, МОРДОВСКИХ НАРОДНЫХ СКАЗОК
Авторский коллектив:
Азат Ганиев, Ирек Шарипов, Дмитрий Гиацинтов, Сергей Киатров - АНО «Татарское детское издательство» (Республика Татарстан)
Руководитель Федерального агентства по делам национальностей И.В. Баринов

«Татар Балалар Нәшрияты» проекты Милләтләр эшләре буенча федераль агентлыкның VII Бөтенроссия иҗтимагый премиясе конкурсында җиңде. Татар, рус, мари, чуаш, удмурт, эрзя һәм мукшы халык әкиятләре буенча «Идел буе батырлары» нәфис-анимацион басмалар сериясе елның иң яхшы наширлек проекты дип танылды.

«Идел буе батырлары» әкиятләрендә Идел буенда яшәүче төрле халыкларның баһадирлары – Камыр-батыр, Вольга, Маршан, Сабан, Йаван-паттар, Сельта балаларны батырлыкка, үзара ярдәмләшүгә өйрәтә, милли гореф-гадәтләр турында сөйли. Һәр халыкның әкияте аның үз телендә, шулай ук рус һәм татар телләрендә язылган. Китапның һәркайсы буенча мультфильм да төшерелгән. Аларны китап тышлыкларында урнаштырылган QR-кодлар аша карарга мөмкин.

Анимация компоненты әлеге проектның мөһим өлеше булып тора, ул балаларны Идел буе халыклары фольклоры дөньясына тагын да ныграк җәлеп итә, дип ассызыкладылар «Татар Балалар Нәшрияты»нда.

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе проектны гамәлгә ашырырга ярдәм итте.

Җиңүчеләрне Милләтләр эшләре буенча федераль агентлыкның җитәкчесе Игорь Баринов «Россия Федерациясендә тел сәясәте» форумында бүләкләде. Конкурска илнең 57 субъектыннан 252 гариза килгән иде.

Үткәннәргә кайту юлында

Г.Тукай әдәби музеенда Татарстанның халык рәссамы, педагог Мөдәррис Миңһаҗевның «Кайту» дигән күргәзмәсе ачылды һәм кылкаләм остасының 70 еллык юбилеена багышланган әдәби-музыкаль кичә булып үтте.

Күргәзмәдә рәссамның 25 картинасы тәкъдим ителә. Алар – авторның төрле жанрдагы иҗади эшләре. Күпчелекне туган җир табигате, җанга ятыш көнкүреш әйберләре, милли ядкарьләр тәшкил итә. Тел, әдәбият һәм сәнгать иститутының өлкән фәнни хезмәткәре Людмила Шкляева искәртеп үткәнчә, күргәзмәдәге картиналарда – татар тормыш-көнкүрешенең күңелгә якын, рәхәт, сәгадәтле мизгелләре. Аларда – яшәешнең сакраль мәгънәләре, туган җир табигате, татар халкының югары мәдәнияте, рәссам тарафыннан кабул ителгән һәм теркәлгән мирас. «Мөдәррис Миңһаҗев – үзенчәлекле рәссам. Ул картиналарында халыкның җан сиземләвен чагылдыра алган. Визуаль образларда кул эше осталарның әсәрләре чагылдырыла, кемдер чиккән, уеп бизәкләгән, үзенең яшәешен ямьләндергән. Әмма вакыт бара, барысы да үзгәрә. Биредә рәссам буыннар истәлеген теркәп калдыра. Шушы рәвешле бизәкләргә салынган, образларда бирелгән тарих булдырыла», – диде Л.Шкляева. Ул су агымының вакыт агышын белдерүен аңлатты. Шул ук вакытта татар далаларындагы кылганның салмак кына хәрәкәтен дә күрергә мөмкин. М.Миңһаҗевның әсәрләрендә татар халкы мәдәниятенә, аның сәгадәтле тормышына хас барлык этаплар чагылдырыла.

Тарих фәннәре докторы, «Европа-Азия» Халыкара Гуманитар Академия президенты, Тынычлык мәдәнияте институты ректоры (ЮНЕСКО) Энгель Таһиров М.Миңһаҗевның иҗаты халкыбызны тетрәндергән елларда күңел-ләргә килеп керүен искәртте. «Аның картиналары кылкаләм белән түгел, йөрәге аша языла. Рәссамның дулкынландыргыч әсәрләренең бар сере дә шунда», – диде ул. Галим М.Миңһаҗевның рәссам-философ булуына да игътибарны юнәлтте. «Аның бер генә дә очраклы картинасы да юк. Ул нәрсә генә сурәтләсә дә, ата-бабаларының җиһазларынмы, самавырларынмы һәм тормыш итә торган элементларынмы – барысына да философик караш ташлап

●Сулдан уңга: М.Минһаҗев, Э.Таһиров.

иҗат итә. «Бу җилпучлар, ат дирбияләре, әбиләребез кигән күлмәкләр, эш кораллары, шул ук сандыклар һ.б. – алар китә, аңлыйсызмы?», – дип дәшә рәссам. Ул мәңгелек эзләнү юлында. Ул – җиңүче. «Халыкның кем икәнен, аның үткән юлларын, Алтайдан башлап, Кытай тирәсендәге беренче дәүләтләребезгә кайтара безне Мөдәррис», – дип тәгаенләде Э.Таһиров.

Тукай әдәби музее мөдире, филология фәннәре кандидаты Гүзәл Төхвәтова М.Миңһаҗевның әдәби музейның бик күптәнге якын дусты булуы турында сүз алып барды. Аның иң беренче күргәзмәләренең берсе дә Тукай музеенда тәкъдим ителгән. Ул М.Миңһаҗевның яшь чагы, әле каләм тирбәтә, татар халкы тормышына багышланган эшләрен ясый башлаган чоры була. Хәзер инде ул – татарның милли сәнгатендә үз урынын тапкан, иҗаты Татарстан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Бакчасарай, Симферополь һ.б. шәһәрләрдә сәнгать сөючеләргә күрсәтелгән тәҗрибәле, рәсем сәнгате остасы буларак музейда кабат үз иҗатын тәкъдим итә. «Аның эшләрендә миллилек ярылып ята. Монда таңнар атышы, кояш чыгышы, татар авылларының ишек аллары, өй түбәләре сурәтләнә. Мөдәррис абый үзе дә иртәнге таң кебек якты, мөлаем шәхес», – ди Г.Төхвәтова. Рәссам белән эшләү бик җиңел. Ул музейга балалар күргәзмәләрен урнаштырганда да ярдәмен тәкъдим иткән. 1 нче һәм 7 нче рәсем сәнгате мәктәбе директорлары да М.Миңһаҗевка еш мөрәҗәгать итә икән. Ул булачак рәссамнар белән аралаша, аларга милли рухта иҗат итү юнәлешендә татар җанлы итеп иҗат итү юнәлешендә киңәшләрен бирә. Рәссам балаларга фикерләрен аерым сүзләр белән генә түгел, ә татар әдәбиятының матур җәүһәрләре, шигырьләре аша да җиткерә.

Быелгы күргәзмәдә Тукай әдәби музее өчен кызыклы табыш та булган. «Моңсу көй» дигән картинада Дәүләт Камил улы Төхвәтуллин сурәтләнгән. Ул – Камил Мотыйгыйның (Г.Тукайның укытучысы) оныгы. Рәссам аның белән 1987 елда Түбән Кама шәһәрендә очрашкан. Дәүләт ага М.Миңһаҗевнә үзенең зыялы, милли кыяфәте белән җәлеп иткән.

Археолог, тарих фәннәре докторы Фаяз Хуҗин да рәссамның үз халкына, аның тарихына ихтирамы, милли традицияләргә тугрылыгы күргәзмәдә тәкъдим ителгән ителгән эшләренең төп эчтәлеген билгеләвен әйтте. «Аның иҗаты тарихыбыз белән сугарылган. «Хәтер» картинасын «милли җәүһәр» дип атарга да мөмкин. Кеше гомерендәге бер мизгел бу, әмма шунда аның барлык үткәне чагыла», – диде галим.

Әдәби-музыкаль кичәдә бик күп журналистлар, музыкантлар, җырчылар, сәнгать әһелләре катнашты.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы.

●РФ Төзелеш министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2023 елда илдә барлыгы 104 миллион квадрат метр торак файдалануга тапшырылган. Барлыгы 3,2 миллион гаилә торак шартларын яхшырткан, шулардан 90 проценты – ипотека хисабына. Пандемиядән соң Россиядә хосусый торакта яшәргә теләүчеләр арткан – бу турыда гражданнарның 67 проценты хыяллана икән.

●РФ Авыл хуҗалыгы министры урынбасары Оксана Лутны әлеге тармактагы кадрлар кытлыгы борчый – агросәнәгать комплексында 200 меңнән артык белгеч җитми икән, ул моның сәбәбе эш хакының аз булуында, дип саный.

● Россия төбәкләрендә мобиль интернет тизлеге акрыная. Сәбәбе: кәрәзле элемтә челтәрләре өчен кирәкле җиһазлар җитешми – аларның барысы да диярлек башкалага җибәрелә. Мәскәүдә исә хәл бик шәп: быел гына да интернет тизлеге 20 процентка арткан һәм секундына 63,2 Мбит тәшкил итә.

Өмми Кәмал мирасы

Шагыйрьнең ата-анасы куйган асыл исеме – Исмәгыйль. Әмма ул сүз сәнгатендә, рухи дөньяда Өмми Кәмал атамасы белән танылa. Аның һәр шигырендә диярлек бу тәхәллүс әдәби кушамат рәвешендә кулланыла.

Бу күренекле затның гомер юлы 1390-1475 елларга нисбәт ителә. Туган, яшәгән урыннары хакында төгәл мәгълүматлар юк. Кайберәүләр аны Әстерханда дөньяга килгән дип карый. Өмми Кәмал – яшәү рәвеше, фикер-карашлары, иҗаты белән суфыйчыл, дәрвиши зат. Андый шәхесләр күченеп, яшәү урыннарын алыштырып тора. Бу төр сыйфатлар, эш-гамәлләр шактый авыр, катлаулы, каршылыклы чорда яшәгән Өмми Кәмал өчен дә хас. Фәнни әдәбиятта аның Идел-йортта, Төньяк Кавказда, шактый еллар Кырымда тереклек кылуы, гомеренең ахырын Кече Азиядә уздыруы телгә алына. Әдипнең Конья шәһәре тирәсендә җирләнүе хакында да фикерләр бар. Төрекчә хезмәтләрдә ул күбрәк Төркия шагыйре буларак карала.

Өмми Кәмал – төрки-татар дөньясында инде берничә гасыр буена бик билгеле каләм әһелләренең берсе. Аның шигырьләре Идел-йортта кульязмаларда, XIX йөз ахырларыннан басма рәвештә гаять киң таралыш таба. 1884, 1898, 1899, 1906 елларда Казанда нәшер ителгән басмаларының зур тиражлар белән дөнья күрүе дә күп нәрсә хакында сөйли. Миңа студентлар белән Идел-йортның милләттәшләребез яшәгән төрле төбәкләренә фольклор, археографик экспедицияләргә чыгарга туры килде. Шул сәфәрләр вакытында Өмми Кәмал әсәрләренә тап булып, аларны, нигездә Казан университеты китапханәсенә тапшыра килдек. Шагыйрь хакында фәнни мәкаләләр дә язарга насыйп булды. Аның тормышы һәм иҗаты турында без фәкыйрегез төзегән дәреслек-хрестоматияләрдә дә махсус бүлекләр бар.

«Коръән»гә, ислам кануннарына ныклап таянган Өмми Кәмал Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Кол Гали, Хисам Кятиб һ.б. гомумтөрки, төрки-татар шагыйрьләренең традицияләрен дәвам иттерә, Әл-Мәгарри, Имам Газзали, Фәридеддин Гаттар, Җәләледдин Руми кебек Шәрык классиклары казанышларыннан да иҗади файдалана. Үз чиратында аның иҗаты Колшәриф, Мәүла Колый, Шәмседдин Зәки, Әбелмәних Каргалый, Дәрдемәнд кебек каләм әһелләренең шигъриятенә көчле йогынты ясый.

Өмми Кәмал тематикасы галим-голяманың да игътибарын җәлеп итеп килә. Төркиядә аның аерым әсәрләре басылган, фәнни-мәгълүмати язмалар да бар. Татар дөньясында бу шагыйрьне чын мәгънәсендә фәнни өйрәнү узган гасырның икенче чирегендә генә башлана. Язучы һәм галим Мөхәммәд Галинең (1893-1952) «Совет әдәбияты» журналында басылган (1941, № 5) «Өмми Кәмал» исемле мәкаләсе – шуның матур бер үрнәге. Бу язмада Урта гасыр әдибенең тормышы, мирасы, әсәрләренең кайбер идея-эстетик үзенчәлекләре, теле, таралышы турында мөһим генә фикер-күзәтүләр бар. Әмма бу гыйбрәтле башлангыч нитектер үстерелми, дәвам иттерелми торды. Бары дистә еллардан соң гына галимнәр (Ш.Абилов, Г.Хөсәенов, Ф.Яхин, М.Әхмәтҗанов, Ә.Сибгатуллина һ.б.) Өмми Кәмал тематикасына мөрәҗәгать итә башлады. Шагыйрь антология-дәреслекләрдә, төрле белешмәлекләрдә дә урын алды.

Әдәбият фәнендә шундый бер хакыйкать күзәтелә: һәр әдипнең диярлек үзенең төп тикшерүчесе була. Мөхәммәдьярның – Шакир Абилов, Мәүла Колыйның – Камил Дәүләтшин, Галимҗан Ибраһимовның – Мансур Хәсәнов, Фатих Кәримнең – Зәет Мәҗитов һ.б. Урта гасыр шагыйре Өмми Кәмал да озак еллар буе шундый затны зарыгып көтә. Һәм, ниһаять, андый галим пәйда була. Ул – 1964 елның 29 декабрендә Башкортстанның Илеш районы Иштирәк авылында туган, шундагы татар мәктәбендә укыган Фаил Камил улы Фәтхетдинов. Аның биографиясе шактый бай: мәктәптә укытучы булып эшли, Совет Армиясендә хезмәт итә. 1991 елда Башкортстан дәүләт университетының татар-урыс бүлеген тәмамлый. Шунда һәм педагогия институтында әдәбият укытучысы. 1994-2001 елларда Уфадагы «Өмет» гәҗитенең баш мөхәррире. 2001 елдан хәзергәчә, ягъни чирек гасырга якын Башкортостандагы «Кызыл Таң» газетасын җитәкли. Күпсанлы журналист кадрлар тәрбияләүгә дә зур өлеш кертә. Күренекле, тәҗрибәле журналист булу өстенә, Фаил әфәнде әдәбият галиме дә. Ул 1990 елларда Башкорт университеты доценты, Борынгы һәм Урта гасыр әдәбияты белгече Камил Дәүләтшин җитәкчелегендә Өмми Кәмал иҗаты буенча диссертация яза, аны уңышлы яклап, 2002 елда филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була. Ф.Фәтхетдиновның шактый гына мәкалә-хезмәтләре, китап-әсбаплары бар. Аларның төп өлеше Өмми Кәмалга мөнәсәбәтле. Шунысы мөһим: галим диссертациясенә тугры калды, бу шагыйрь турында фәнни эшчәнлеген дәвам иттерде, тагын да тирәнәйтте. Нәтиҗә буларак 2022 елда Ф.Фәтхетдиновның Казанда гаять саллы, күләмле (648 бит; 52,7 табак) хезмәте дөнья күрде. «Книга Умми Камала... Өмми Кәмал китабы» дип аталган бу монография Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты гыйльми Советы карары белән басарга тәкъдим ителгән (Рецензент-бәяләүчеләре – филология фәннәре докторлары Р.Әмиров һәм Л.Дәүләтшина). Бу саллы хезмәт Ф.Фәтхетдиновның 30 еллык тикшеренүләренең тулы бер йомгак-нәтиҗәсе дә булып тора [2024 елда авторның тууына 60 ел тула. Бу китап шул истәлекле датага үзенә күрә бер бүләк тә].

Гыйлемнең башка тармакларындагы кебек, филология фәненең дә үз кыенлыклары, хосусиятләре бар. Тукайгача чор әдәбиятны өйрәнгәндә алар аеруча күп: элеккеге графикаларны белү, кульязмалар белән эшләү техникасы, диннән, тарихтан, Шәрык кыйммәтләреннән хәбәрдар булу, гарәп, фарсы, төрки телләрен билгеле бер дәрәҗәдә белү һ.б. Фаил Камил угылының бу юнәлештә шактый хәзерлекле һәм тәҗрибәле булуы аның әлеге китабында яхшы сизелеп тора. Аерым очракларны, хосусый деталь-күренешләрне исәпкә алмаганда, авторның фикер-аңлатмалары артык бәхәс тудырмый, кабул ителә.

«Өмми Кәмал» китабының монографик характердагы тәүге кисәгендә (3-128 б.) урыс һәм татар телләрендә шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты яктыртыла. Ике телдәге бу текстлар эчтәлекләре белән, нигездә, үзара туры килә. Аларда Өмми Кәмалның өйрәнелү тарихы, тәрҗемәи хәле, кульязмалары, басмалары, әсәрләренең идея-эстетик үзенчәлекләре, тел-стиле, традицияләре киң планда, комплекслы яктыртыла. Китап авторы төрле чыганакларга, шагыйрь әсәрләренең кульязмаларына таянып, әдипнең хәзергә 140 тан артык шигыре билгеле булуын искәртә. Хезмәтнең 129-264 нче битләрендә шагыйрьнең гарәп графикасындагы әсәрләре (факсимилесы) урнаштырылган. Төп текст итеп Өмми Кәмалның 1898 елгы Казан басмасы һәм 1837 елда Чиләбе төбәгендәге «Сафакүл мәдрәсәсе»ндә күчерелгән кульязмасы алынган. Китапның 265-426 битләрендә шагыйрь әсәрләренең транскрипциясе бирелгән. Өмми Кәмал шигырьләренең теле бүгенге укучы өчен шактый авыр. Аларда гарәп-фарсы сүзләре, архаик формалар еш очрый. Ф.Фәтхетдинов шагыйрь әсәрләрен хәзерге телгә тәрҗемә итеп бирүне дә кирәк тапкан (427-591 битләр). Хезмәтнең кушымта рәвешендәге бер бүлеген «Өмми Кәмал шигырьләрендәге борынгы төрки, гарәп, фарсы сүзләренең аңлатмалары» тәшкил итә. Китап бай гына «библиография» белән ябыла.

Өмми Кәмал шигърияте лирик характерда. Автор Урта гасыр поэзиясенә хас булган шигъри форма-жанрларны (мөнәҗәт, мәрсия, мәснәви...) иркен куллана. Аллага, пәйгамбәрләргә, остазларга багышламалар да бар. (Әмма хөкемдарларга – юк). Нигездә, икеюллык строфалар белән яза. Шигырьләрдә аларның саны төрлечә. Күпчелеге 10-20 строфалы. Арада 150 дән артык икеюллыкны эченә алган шигырьләр дә очрый. Алар саннар белән генә бирелгән. Автор гаруз, аның төрле үлчәмнәре-калыплары (һәзәҗ, рәмәл...) белән яза, эндәш-мөрәҗәгать, кабатлау, риторик сорау, анафора, рәдиф кебек поэтик чаралардан уңышлы файдалана. Мәсәлән, «Әй әүвәл ахры мәгъмүр Мөхәммәд» шигыренең («69 нчы») һәр 26 юлы «Әй..» сүзе (юлбаш анафорасы) башланып китә (365 б.). 57 нче сан астында бирелгән мактау-мәдехнең 34 строфасы (икеюллыгы) да рәдиф булып килүче «ля иляһә илляллаһ» сүзләренә тәгәлләнә.

Өмми Кәмал шигърияте гомумән дини-суфыйчыл рухта. Шуңа тапкыр рәвештә китап авторы шагыйрь мирасын, идея-сәнгати планда махсус бүлекләрдә җентекле анализлый. Андагы төп тема-идеяләрне, мотивларны поэтик як белән тыгыз бәйләнештә тикшерә. Хезмәттә лирик герой, аның эчке дөньясы, уй-кичерешләре хакында кызыклы фикер-күзәтүләр бар. Автор шагыйрь иҗатының фәлсәфи табигатьле булуына игътибар итә. «Пантеизм», «иляһи мәхәббәт» мәсьәләләре дә җентекле яктыртыла.

Шунысы мөһим: Өмми Кәмал мирасы киң әдәби-тарихи контекстта, әдәби бәйләнешләр яссылыгында карала, гыйбрәтле чагыштырулар ясала. Шуның нәтиҗәсендә шагыйрь иҗатының асылы, рухи дөньядагы урыны һәм роле тагын да тулырак ачыклана.

Гомумән, «Өмми Кәмал китабы» хакында озаклап сөйләргә, күпләп язарга мөмкин булса да, сүзебезне хәзергә туктатып торабыз. Йомгаклап янә шунысын әйтәсе килә: бу басма – гаять күп көч түгелеп, озак еллар дәвамында язылган, докторлык диссертацияләре таләпләренә җавап бирерлек җитди хезмәт. Ул, бер яктан, Өмми Кәмал кебек олуг шагыйрьнең әсәрләре, шигъри дөньясы турында тулы бер күзаллау тудырса, икенче яктан, рухи мирасыбызны, әдәбият тарихын алга таба ныграк тикшерүгә дә этәргеч бирә, уңай йогынты ясый.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,
филология фәннәре докторы.

Өметле шигърият



Яр Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче шагыйрь Айрат Шәйхетдиновның Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Көмеш төн» (2023) китабындагы шигырьләре белән танышкач, күңелгә үзгә бер яктылык үтеп кергәндәй булды, чемердәтеп, тән буйлап рухи җылылык йөгерде, җанда ышаныч, өмет артты. Шигырьдән-шигырьгә күчәсең һәм авторның ихлас хисләренә, аның йөрәге аша узган берара тымызык күл кебек, берара ярсу, шаулы тау елгасы шикелле, берара язгы яшендәй дөньяны балкытып куйган тойгыларына таң каласың. Чыннан да, шагыйрь күңеленнән ургылган моң игътибарны тарта, сүзләрнең сәйлән төймәләре сыман тезелгән, йә булмаса туган илләрен сагынып кайткан кыр казлары зәңгәр күк киңлекләрен айкап барган кебек бер-бер артлы матур гына тезелеп килүе, шигырь юлларының илаһи аһәңе сокландыра:

Синсез тормыш ямен тапмыйм,
Офыклар да тар гына.
Дөньяда гүя яшәмим,
Мин дөньяда бар гына.

(«Миңа җитми иркә-назың...»)

Авылымның таулары юк,
Чишмәләр акмый ургып.
Ә миңа ул – иң якты җир,
Анда үскәнмен туып.

(«Авылым»)

Айрат Шәйхетдинов шигъриятендә бәхетле һәм бәхетсез, шул ук вакытта җавапсыз мәхәббәт, ялгызлык, туган якны ярату, әнкәйне олылау, яшьлекне сагыну, гомумкешелек кыйммәтләре турында уйлану төп урынны алып тора. Югары камиллектәге хисләр ясалышында, фәлсәфә белән беррәттән, нечкә юморга да урын табыла. Арада шагыйрь каләменнән төшкән афоризмга тиң юллар да бар:

Колга ирек кирәк түгел,
Кол хөррият дауламый.
Колның аңы азатлыкның
Ни икәнен аңламый.

(«Кол»)

И хатын-кыз, и гүзәл зат,
Күңелнең хисле җыры!

(«Матурларның матуры син...»)

Шагыйрьнең «Әллә төштә, әллә өнемдә» шигыре күңелне аеруча тетрәндерә. Гомере буе кешеләргә хезмәт итеп, картаймыш көнендә өйдән куылган эт язмышы аша адәм затларының бер-берләренә мөнәсәбәтен дә чагылдыра кебек. «Төш» шигыре исә милләтебезнең үткәнен һәм бүгенге халәтен бәян итә.

Гомумән алганда, Айрат Шәйхетдинов шигъриятен мәхәббәтле һәм өметле шигърият дип атыйсым килә. Яхшылык, ярату, бәхет барыбер өстен чыга. Һәрвакыт шулай булсын!

Ленар ШӘЕХ,
шагыйрь,Татарстанның
атказанган сәнгать эшлеклесе.

Таралган ил кыйссасы

XV Бөтенроссия яшь режиссура фестивалендә Туймазы Татар дәүләт драма театры күрсәткән «Борһан йорты» спектакле күңелгә тирән уелды.

Анда сүз гел Борһан турында бара, әмма ул үзе инде – гүр иясе. Балалары аның рухына догалар укып, ашлар уздыру белән мәшгуль. Бөтен борчулары – шулпа тәмле булсын да, токмачлар укмашмасын. Әтиләре үлгәнгә әлләни кайгырмыйлар да кебек.

Борһан үзе бар да, юк та. Сәхнәдә күренмәсә дә, без аны һәр баланың яралы язмышы аша күргәндәй булабыз. Әтисенең каты куллыгына түзә алмыйча 16 яшендә туган авылдан чыгып киткән Байназарның, ирсез көе балага узганы өчен өйдән куылган Банатның, әтисе аркасында яшьлек ярына өйләнә алмый калган, бүген исә аның кебек үк кырыс кешегә әйләнгән Баязитның, 1990 елларда бизнес оештырып җибәргән һәм әтисенең хәер-фатихасы белән компаньонын үтергәннән соң эчүгә сабышкан Байбулатның бәхетсезлекләренә кем гаепле? Әлбәттә, Борһан. Ә гаебе нәрсәдә? Балалары өчен таза имән бүрәнәләрен сайлап, зур йорт төзегән. Шулмы гаеп? Бай, таза тормышта яшәүләрен теләп, һәркайсына «Ба» авазларыннан башланган исемнәр биргән. Бу да гаеп түгел сыман. Хатыны үлеп киткәч, балалары ана назына тилмермәсен өчен, үзеннән шактый яшь булса да, Әминәне алып кайтып та дөрес эшләгән кебек. Артык каты куллы, кырыс булгандыр, бәлки. Ләкин балалар әдәп-әхлакны белеп үссен, ата-бабалары исеменә тап төшермәсен өчен шулай кирәк. Аның каравы балалары гына түгел, бөтен авылдашлары Борһан исеменнән өркеп, сүзе белән санлашып, үзен хөрмәт итеп яшәгән. Ничек кенә булмасын, үзе үлгәннән соң Борһан йорты барыбер тарала, аннан бәрәкәт китә, бериш геройлар исә фаҗигале үлемгә дучар була.

Йортның какшавы бетеп барган авыллар, онытылган гореф-гадәтләр, гасырдан-гасырга тапшырыла килгән яшәү тәртипләренең җимерелүе, милләтне милләт иткән кыйммәтләрнең югалуы турында уйга сала. Зират агачларын кисеп сатулары, киселгән агачлар урынына чытырманлык үсеп чыгу, ата-баба каберләренә юллар каплану да буыннар дәвамчылыгы өзелүнең бер билгесе буларак аңлашыла. Зират агачлары киселгәч, Борһан йорты янындагы шомыртны сырып алган кара каргалар, аларның ямьсез тавыш белән кычкыруы да хәерле фал түгел. Кәнтәйләр яныннан кайтып кермәгән ире Кәлимулла аркасында акылдан шашкан Зәйнәп карчыкның «мин үлгәч өем этләргә кала» дип ачынуы, ахыр чиктә йортына ут төртеп яндыруы да бетү, таркалу идеясен көчәйтә. Балалары авылдагы кечкенә өенә кайтарып ташлаган Бәдерхәят әбинең исә зур йортта яшәп калу турында хыяллануы шулай ук аталар һәм балалар мөнәсәбәтләре аша традиция какшауны тирәнрәк тоярга мөмкинлек бирә. Гомумән, бу Борһан йортында берәр бәхетле кеше бармы соң? Әминә карт кыз көе Борһанга икенче хатын булып кияүгә чыкса да, гомере буе классташы, Борһанның улы 16 яшендә авылдан табан ялтыраткан Байназарны яратып яшәгән. Аның кызы Фирүзәнең җиләк кебек пешкән чагы. Әмма әтисе урынына калган Баязит абыйсы аның яныннан егетләрне гел куалап тора, шулай икән, аның да бәхетле булуы бик икеле. Ә Баязит соң? Яшьлегендә сөйгән яры Айсылуга өйләнергә киртәләр юк ич, Борһан үлде. Матур тормыш корып, алар бәхетле булмасмы әле? Баксаң, Борһан кемнең кем икәнен алдан чамалаган булган. Айсылу бүген – җирәнгеч Кәлимулла кәнтәйләренең берсе һәм карынындагы бала да Кәлимулланыкы...

Борһан газиз балаларын абыннан саклаган булып чыга түгелме соң? Шулмы аның хатасы? Юк, үз башлары белән яшәргә мөмкинлек бирмәве, каты кулы белән буйсындырырга тырышуы нәтиҗәсендә таркалды аның йорты. Чынлыкта, йортны терәү сыман Борһанның авторитарлыгы, буйсындыру көче генә тотып торган. Ул үлгәч исә ничек яшәргә белмәүче бәхетсез балалары төрле якка тарала. Гаилә түгел инде алар. Гаилә булсын өчен ярату, ярдәмләшү кирәк. Болар исә бу хисләрнең ни икәнен дә белми...

Таралган Борһан йорты какшаган илне гәүдәләндерә. Тоталитаризмның аяныч нәтиҗәләрен тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Бу искиткеч спектакльне режиссер Айдар Зарипов, рәссам Булат Ибраһимов, ут көйләүче оста Илшат Сәяхов, композитор Вәсил Гафаров куйган. Рольләрне А.Солтанов (Байназар), А.Зәйлалов (Кәлимулла), А.Вәлиева (Айсылу), Г.Латыйпова (Әминә), Д.Нуриханов (Баязит), Д.Вахитова (Фирүзә), Л.Сөләйманова (Зәйнәп), Р. Сәлимгәрәева (Габделхәят), Ф.Мөхәммәтдинов (Байбулат), Д.Гыймадиева (Банат) уйный. Туймазы театрында озын буйлы, мәһабәт, күңелгә кереп кала торган ир-ат артистлар байтак икән. Бөтен авылда дан тоткан Борһанның балаларын шундый актерлар уйнарга тиеш тә инде.

Спектакль барышында күз алдыннан классикларыбыз җанланып узды. Кем әсәре соң әле бу, дип баш ватарга туры килде. Мондый җитди темаларны күтәрү һәм оста итеп сюжетны кору бары тик классиклар кулыннан гына килә. Әсәрдәге һәр сүз очраклы түгел һәм кирәксезгә әйтелми. «Өем этләргә кала», дигән реплика һаман колакта чыңлап тора. Кызык, безнең тамашачыны надан, артта калган, комедияләр генә ярата, ди бериш режиссерлар. Күрсеннәр иде алар «Борһан йорты»н ничек бирелеп карауларын! Миңгерәүләткәч, кем дә түбәнәя. Режиссерларга мәгънәле, җитди, еллар узгач та кыйммәтен җуймый торган әсәрләр сайлыйсы да бит. Юк, тамашачы гаепле, имеш. Ә иң кызыгы, бу пьеса барыбызга да яхшы таныш драматург, режиссер Илгиз Зәйниевнеке булып чыкты. Ул 2016 елда «Яңа татар пьесасы» бәйгесендә беренче урынга лаек булган. Аннан соң аны Буа театрында режиссер Лилия Әхмәтова сәхнәләштергән. Әмма ул кыска гомерле булып чыккан, чөнки спектакльдәге өметсезлек, чарасызлык рухы Буа театрының сәнгать җитәкчесе Раил Садриевнең күңеленә хуш килмәгән. Тамашачылар исә Илгизне җиңелчә комедияләр иҗат итүче буларак шәбрәк белә. Күр әле, нинди җитди, тирән уйларга этәргән, теләсә кайсы театр сәхнәсен бизәрлек әсәрләре бар икән бит! «Борһан йорты», һичшиксез, академия театры сәхнәсендә куелырга тиеш иде. 2016 елдан бирле җиде ел буена әрәм булып яткач, «Яңа татар пьесасы» бәйгеләрен ни өчен уздырабыз соң без?!

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.
Гүзәл САФӘРГАЛИЕВА фотолары.

Рифат ҖАМАЛ

Күңелемнең карлы-бозлы чагы – Бураннар да сары томаннар...

* * *
Арабыз да юкса шундый якын,
Тик күңелең миннән еракта.
Ул күңелгә барып җитеп булмас,
Бу дөньяны урап-урап та.

Минем хисләр көлке синең өчен –
Миңа килгән, сиңа килмәгән.
Кемгә җиңел, кемгә авыр икән –
Ансын гына һичкем белмәгән.

Сине сөйгән өчен, авыр сүзләр
Ишеттем мин синең үзеңнән.
Күңел тынычлыгын шуннан торса,
Югалырмын синең күзеңнән.

Йөрәк тынды, тынычланды күңел,
Төшләремә инде кермисең...
Синең күктә ялгыз йолдыз сүнде,
Ә син шуны һаман күрмисең.

* * *
Нәрсә көтә иртәгесен –
Кемнәр белә?
Билгесезлек җанны кыйный,
Җанны телә.

Ә бүгенгә мин оҗмахта –
Кочагыңда,
Дөрләп янам синең яшьлек
Учагыңда.

Мин дә яшьмен. Һич картаймам
Синең янда.
Әйтерсең лә мин туганмын
Әле яңа.

Шундый чагым – сине күреп
Һушым киткән...
Әллә яшәү мәгънәсе дә
Шушы микән?!

* * *
Гомер ике килми, диләр –
Сөю дә шуның кебек...
Кемдер әйткән: «Бер елгага
Булмыйдыр ике кереп».

Ә нигә соң, сине күреп
Ничәмә-ничә елдан,
Яшьлегемә кайттым кире,
Борылып, барган юлдан.

Чәчләрең ап-ак булса да,
Күзләрең кара килеш...
Җырларыңа моң тулса да,
Тавышың – серле инеш!

Күз читеңдә җыерчыклар
Бозмыйлар елмаюың...
Икәү бергә урап кайтыйк
Яшьлекнең урау юлын!

«Кабат гашыйк булдым!» дисәм,
Дөрес булмастыр сүзем.
Гомерем буе сине сөйдем,
Белмәдем генә үзем.

* * *
Бар да сагыналар үткәннәрне,
Кире кайтып янә үтмәкче,
Су астында калган тугайларда
Томандагы ярны үпмәкче.
Күпләр калды инде үткәннәрдә –
Һәркайсысы күңел түремдә.
Якыннарым, яшьли сөйгәннәрем,
Яратамын сезне бүген дә.
Ләкин яшим бүгенгесе белән –
Шатланам да янам, көенәм.
Янәшәдә күпме якыннарым,
Яратамын, сөям, сөеләм.
Ничек ташлап китим мин аларны,
Үткәндәге ярны үбәргә?
Бар теләгем – алда калган юлны
Бүген сөйгән белән үтәргә.

Тик тормыш бит, каһәр,
Матурла шулкадәр!
Онытам кыйнаганны,
Сагынам сыйпаганны,
Һаман да күңелдә
Җирнең кыз баласы.
Хур кызы янына
Килмидер барасы!

* * *
Бар да үтә, ләкин бар да
Онытылмый бөтенләй,
Әйтерсең лә сүнгән учак
Акрын гына төтенли.

Ышанмасаң, яшьлегеңә
Син бер борылып кара.
Искә төшә яшьли сөйгән,
Ябылмый татлы яра.

Һәр кич саен серләшкәннәр,
Күңелдә сөю җыры...
Тик бер кичне (ни хикмәттер?!)
Кыз аланга килмәгән.
Егет кеше үпкәләгән,
Чын хәлне шул белмәгән.
Иртән – «сугыш!» Килгән кәгазь,
Еракларга чакырып.
Киткән егет авылыннан,
Акбүз атын чаптырып.
Имән кебек япь-яшь егет
Үлем бар дип белмәгән,
Андый уйлар, ничә ятып,
Төшенә бер кермәгән.

Ә сөйгәне кичә иртән
Әбиләренә киткән,
Дәү әнисе авыргачтын,
Кайталмаган, кичеккән.

* * *
«Кырык яшем. Инде акыл кергән,
Хисләрем дә әле китмәгән.
Әллә язым, әллә инде көзем,
Һаман әле нидер җитмәгән», –
Диеп язган идем кичә генә.
Алтмыш тулды. Сирәк сулыймын.
Ә шулай да язгы ташкын кебек
Ярсу әле, тулы сулымын.
Шулай диеп язган идем иртән,
Ун еллык көн үткән дә киткән.
Инде җитмеш. Йөрәк ярсу әле...
Бәлки, инде китәр чак җиткән.
Кайда икән гармун, кулга алыйм,
Уйный белмәсәм дә җырлармын.
«Без китәбез, сез каласыз» диеп
Яңгыратып урман-кырларны.
Бер биергә иде кызлар белән,
Егылганчы алар арудан.
«Ничек китим сезне калдырып?» дип,
Түбәтәйне бәреп ярсудан...

* * *
Күңелемнең карлы-бозлы чагы –
Бураннар да соры томаннар...
Күңелемне кемгә ачыйм икән,
Күңелемне, белмим, кем аңлар.

Ачмыйм әле аны беркемгә дә, –
Моң-зарымны кемнәр ишетер?
Шатланырлар ятлар. Якынымны
Күңелемнең бозы өшетер.
Килер әле язлар күңелемә,
Шул чагында дуслар җыярмын.
Күңелләрен сарган боз-карларны
Эретерлек көчем тоямын.

* * *
Мин китәрмен берчак,
Ә бүгенгә борчак
Сибәм, дөнья буйлап,
Юк-бар уйлар уйлап.
Яшим әле, яшим,
Кайвакытта яшьним.
Чибәр кызлар күреп,
Төшә кайчак бүрек.
Әле гаҗәиләнәм:
Язмыш – Галиҗәнап –
һаман әле кыйный,
Кыйнап һич тә туймый.

* * *
Табигатьнең – дүрт фасылы,
Тәүлектә дә дүрт вакыт,
Һәрбер вакыт киләсесен
Җитәкләп килә, алып.

Минем бары ике фасыл –
Бәхетле айлы төннәр,
Сине көтеп, синсез үткән,
Кояш тотылган көннәр.

КАЕН БЕЛӘН ИМӘН

Кара урман аланында
Үсеп утырган Имән,
Янәшәдә – зифа Каен,
Бигрәкләр дә пар килгән!
Имәнне иркәли һәрчак
Ак Каенның тәлгәше.
Әйтерсең лә кыз һәм егет
Йөриләр җитәкләшеп.
Имән саклаган Каенны
Салкын төн җилләреннән,
Күзен алмаган һичкайчан
Үзенең чибәреннән.
Ә кичләрен – пар күгәрчен
Аларның итәгендә...
Кыз егеткә вәгъдә биргән
Мәңгегә көтәренә.
Егет таза имән кебек,
Каендай сылу – кызы...

«Сугыш!» хәбәрен ишетеп,
Авылына йөгергән.
Тик егете-җанкисәге
Инде китеп өлгергән...
Үткән вакыт. Сөйгәненең
Юктыр хаты-хәбәре.
Кыз баланың сагышы зур –
Кемнәр аңлар хәлләрен?!

Түзалмыйча йөрәгенә,
Үзәкләре өзелеп,
Бергә булган гөл-аланга
Барган кызый, йөгереп.
Килсә анда (нәрсә күрсен?!)
Имән кап-кара булган,
Яшелдән яшел яфраклары
Инде бөтенләй сулган.
Кәүсәсендә зур яра бар –
Күмерләнгән, каралган...
Шушы парны – ике ярны –
Кемнәрдер куралмаган.
Җил-давылдан эш чыкмагач,
Яшен бәргән көч белән...
Каенын саклап үлсә үлгән,
Тик егылмаган Имән.
Ак Каенның пакьлегенә
Килмәгән һич тә зыян.
Тик күренә – аппаккайның
Кайгысы бик тә зурдан.
Имәненә – сөйгәненә –
Ул игән тәлгәшләрен –
Агачлар да моңланалар,
Югалтып кардәшләрен.
...Ә кыз бала, нидер сизеп,
Имәнне кочкан-сөйгән.
Йөрәгендә йөрткән назын
Шушы имәнгә биргән.

Кайтса өйгә, ята кәгазь –
«Батырларча...» диелгән.
Илне саклап, кызны яклап,
Егет гомере өзелгән...
Һәр ел саен, яз килүгә,
Аккач та кар сулары,
Китерә кызны аланга
Йөрәге ярсулары.
Сөяләә ялгыз Каенга,
Каен – аның сердәше...
Әллә Каен суы тама,
Әллә инде күз яше...

Эреле-ваклы вакыйгалары белән тагын бер ел узып китте. Ул безгә уңышлар да, беркадәр шатлык-куаныч та китерде, әмма кайгы-хәсрәтләре дә аз булмады. 2023 елда без бик күп олуг шәхесләрне, асыл егет һәм кызларыбызны югалттык. Гомерләрен милләткә багышлаган олуг затларыбызның бер өлешен искә алып үтик.

Сез

Яңа ел башлануга **Минсәгыйть Закир улы Шакировны** югалттык. Ул 27 ел гомерен Чирмешән районын үстерүгә багышлады, 19 ел буе район хакимияте башлыгы вазыйфасын үтәде. Райондагы күп уңышлар аның исеме исеме белән бәйле. 15 гыйнварда, 75 нче яшендә безнең арадан китеп барды.

29 гыйнварда сәламәтлек саклау министры **Марат Наил улы Садыйковны** югалттык. Ул 54 нче яшендә кинәт арабыздан китте. Ул 1918 елдан республика министры иде.

2 февральдә 93 яшь тулырга ике ай калганда **Йолдыз Галимҗан кызы Нигъмәтуллина** вафат булды. Танылган әдәбият белгече, филология фәннәре докторы, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасы дәүләт һәм Бакый Урманче премияләре иясе, Казан университетының атказанган профессоры иде.

26 февральдә 87 нче яшендә **Марат Әшрәп улы Сираев** бакыйлыкка күчте. Ул РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре иде. 1983-1988 елларда республиканың авыл хуҗалыгы министры булды. Ул эшләгәндә авыл хуҗалыгы предприятиеләре техник яктан нык төзекләндерелде.

Җыр сәнгате дөньясы да зур югалту кичерде. Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты **Эмиль Усман улы Җәләлетдинов** вафат булды. Ул филармониядә җырчы-солист булып озак еллар эшләде, концертлар белән Россиянең һәм чит илләрнең төрле почмакларында булды. Аның иҗатында байтак композиторларның әсәрләре урын алып торды.

Балтач районының Чепья авылындагы "Халыклар дуслыгы" музее директоры, сугыш ветераны **Гарифҗан Гали улы Галиев** 96 яшендә вафат булды. Ул районның төрле урыннарында җаваплы эшләрне башкарды, шул исәптән башкарма комитет җитәкчесе дә иде.

Танылган журналист, Татарстан Рәисенең элеккеге матбугат сәркатибе, "Татмедиа" матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары **Эдуард Фәрит улы Хәйруллин** 54 яшендә вафат булды.

РСФСР һәм Татарстанның халык артисты **Вадим Валентинович Кишнер** 14 апрельдә 87 нче яшендә безнең белән хушлашты. Үз гомерендә ул дөнья драматурглары әсәрләрендәге 120 дән артык рольне башкарды.

4 майда виртуоз музыкант-балалайкачы һәм педагог Россиянең халык артисты **Шәүкәт Сабир улы Әмиров** бакыйлыкка күчте. 1990-1999 елларда ул Казан дәүләт консерваториясе ректоры урынбасары, 2003-2010 елларда М.П.Мусоргский исемендәге Урал консерваториясен җитәкләде. Укучылары: Россиянең һәм Татарстанның атказанган артистлары, халыкара һәм Бөтенроссия конкурслары лауреатлары, музыка көлләджлары мөгаллимнәре.

Республиканың киң җәмәгатьчелеге, фән, мәдәният дөньясы зур югалту кичерде, 5 май көнне зур талант иясе, Казан дәүләт университетында 11 ел ректор булып хезмәт иткән **Юрий Геннадьевич Коноплев** арабыздан китте. Ул 84 нче яшендә иде. Университетның физика-математика факультетын тәмамлагач, ул университетта материаллар ныклыгы лабораториясе мөдире вазыйфасын башкарды, 1990 елда ректор итеп билгеләнгән иде.

1997-2004 елларда Татарстанның Казахстанда тулы вәкаләтле вәкиле, Казахстанның "Идел" татар иҗтимагый һәм мәдәни үзәкләре ассоциациясен төзүче **Морат Габделхәй улы Кәримов** 16 майда вафат булды. Ул физиолог-онколог, медицина фәннәре докторы, профессор иде.

21 майда татар яшьләре хәрәкәте ветераны, җәмәгать эшлеклесе, җырчы **Зөфәр Ядкәр улы Сафинны** югалттык. Зөфәр шактый еллар солист буларак Татарстанның Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшләп, Татарстанның атказанган артисты исеменә лаек булган җырчы.

Татарстан Рәисе администрациясе талантлы галим, педагогия дәүләт хезмәтләре ветераны **Аркадий Васильевич Фокинны** югалтты. А.Фокин гомеренең күп өлешен керәшеннәр тормышын өйрәнүгә багышлады. 1994-2023 елларда ул Президент Аппаратының җәмәгатьчелек һәм милләтара мөнәсәбәтләр секторын җитәкләде, керәшеннәренең хөрмәтен казанды.



11 июнь көнне Татарстанның халык артисты, Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең баш дирижёры, композитор, музыкант **Рәшит Шәкүр улы Мостафин** да бакыйлыкка күчте. 14 төрле уен коралында уйный белүче, музыка уен коралларын туплау һәм реставрацияләү белән мавыгучы остазга 77 яшь иде.

1 июль көнне үзенчәлекле шагыйрә һәм прозаик **Нурия Халит кызы Измайлованы** югалту турында кайгылы хәбәр килде. Туксанынчы еллар уртасында тормыш иптәшенә карата эзәрлекләр көчәйгәч, Нурия ханым гаиләсе белән чит илгә күчеп китәргә мәҗбүр була. Океан артында яшәсә дә татарлыгын онытмады, туган телендә язуын ташламады. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, 11 китап авторы.

безнең күңелләрдә...

Татарстанның фән дөньясы филология фәннәре докторы, Россия лингвистик фәннәр академиясе академигы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, озак еллар университетта студентларга татар теле укыткан, аннары ун елдан артык педагогия институтын җитәкләгән **Мирфатых Зәки улы Зәкиев** 96 нчы яшендә арабыздан китеп барды. М.Зәкиев фән һәм техника өлкәсендә күп кенә дәүләт премияләренә лаек булды. Шушы яшькә кадәр ул йога белән шөгыльләнде.

27 августта тагын бер талантлы егетебезне югалттык. **Наил Зиннәтулла улы Зиннәтуллин** күренекле журналист иде. Ул гомере буе республика матбугатында да, шул исәптән “Ватаным Татарстан” газетасында эшләде.



1 сентябрьдә язучы, шагыйрь, журналист **Рашат Мияссәр улы Низамиев (Рашат Низами)** вафат булды. Ул – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, республика язучылар берлегенең Һади Такташ, Шәйхи Маннур премияләре лауреаты. Р.Низами – 16 китап авторы. 1997-2006 елларда “Идел” яшьләр журналының баш мөхәррире булды.

Татарстан Дәүләт Советы президиумы X (1980-1985), XI (1985-1990) һәм XII чакырылышлар Югары Советы депутаты, Казан моторлар төзелеше берләшмәсенең генераль директоры (1983-2004) **Александр Филиппович Павловны** соңгы юлга озатты. А.Павлов кинәт вафат булды. Ул үз эшенең остазы иде.

14 сентябрьдә Татарстанның халык җырчысы **Флера Зыятдин кызы Сөләйманова (Асеева)** 85 нче яшендә арабыздан китте. Ул яраткан эшенә иксез-чиксез тугрылык, зыялылык, изге күңеллеге белән карады. Ул Татарстан радиосыннан да күп кенә артистларның чыгышларын әзерләде. Аның үзенең дә радио һәм телевидениедән чыгышларын халык бик яратып тыңлады. Җырчының кабатланмас тавышына һәркем соклана иде.

8 октябрьдә Татарстанның элеккеге кинематография буенча рәисе **Зөфәр Гариф улы Бохараев** бакыйлыкка күчте. Комитет ябылгач, ул 1995 елдан 2005 елга кадәр Татарстанның мәдәният министры урынбасары булып эшләде.

13 октябрьдә Татарстан Югары Советының план һәм бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиянең элеккеге рәисе **Гелий Васильевич Кобелев** вафат булды. Алабуга шәһәрендә туган, Казан авиация заводында токарь булып эшли башлый. Алга таба ул республиканы социаль-икътисади үстерү, финанс ягыннан тәэмин итүгә бәйле төрле вазыйфалар башкара. 1973 елда Мәскәү район башкарма комитеты рәисе, 1981 елдан партия район комитетының беренче секретаре була.

20 октябрь иртәсендә күренекле җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре, Россия һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, М.Җәлил, А.Алиш, Г.Тукай исемендәге премияләр лауреаты **Разил Исмәгыйль улы Вәлиевнең** йөрәге тибүдән туктады. Ул Әдәбият институтын тәмамлагач, “Ялкын” журналында җаваплы сәркатип булып эшли. Аннары Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары, Чаллы Язучылар оешмасы җитәкчесе, Татарстан Милли китапханәсе директоры булып эшли. Ул 1990 елдан 2019 елга кадәр Дәүләт Советы депутаты булды. Фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр даими комиссиясен җитәкләде.



Россиянең һәм Татарстанның танылган рәссамы, каллиграфия остасы **Владимир Александрович Попов** 27 октябрьдә 100 нче яшендә бакыйлыкка күчте. Ул чирәм җирләрне күтәрүчеләр, табигатьне саклау, КамАЗ төзелеше, нефтьчеләр турында күп иҗат итте.

19 ноябрь көнне Тываның Кызыл шәһәрендә яшь милләттәшебез **Батырхан Әгъзамов** юл һәлакәтендә вафат булды. Мәктәптә укып йөргән чагыннан ук Батырхан милли хәрәкәттә. 2016 елда Татарстан Президенты Р.Миңнеханов Тывага килгәч, ул татарларны җыеп аның белән очрашуга алып бара. Казанда укыган чорда да төрле милли чараларда катнаша, Гаяз Исхакый музеен төзекләндерүне таләп итеп ялгыз пикетлар да оештыра.

Әгерҗе районының элеккеге хакимият башлыгы **Валерий Владимирович Макаров** 2 ноябрьдә 59 нчы яшендә арабыздан китеп барды. Ул 2013 елда район башлыгы итеп билгеләнгән иде. Район белән 7 елдан артык җитәкчелек итте.

Озак еллар Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары булып хезмәт иткән, язучы, шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Дамир Минсәгыйрь улы Гыйсметдиновны** югалттык. Ул 10 ел дәвамында “Азатлык” радиосында хәбәрче булып эшләде, шул ук вакытта язмалары матбугатта да дөнья күрде. Ул укучыларга сатирик, күпсанлы эстрада җырлары авторы буларак та яхшы таныш.



Татарстанның халык рәссамы, график һәм монументаль сәнгать остасы **Рөстәм Әхмәт улы Килдебәков** 90 нчы яшендә вафат булды. Р.Килдебәков монументаль-гамәли сәнгать, графика, гобелен сәнгатендә күпкырлы талант иде. Соңгы көннәренә кадәр Килдебәков үз эшенә, мәдәнияткә һәм сәнгатькә тугры калды.

Ноябрь ахырында Г.Камал театры артисткасы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисткасы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты **Наилә Хәким кызы Гәрәева** бакыйлыкка күчте. Ул театрда үзәк рольләрне башкаручы, тамашачының яраткан артисткаларының берсе иде.

* * *

Гомерләрен халкыбызга багышлаган шәхесләрне онытмыйк, хәтердә яңартыйк. Рухлары рәнҗемәсен. Бакыйлыкка күчкән олуг затларыбызның хезмәтләрен тарихта калдыру, киләчәк буыннарга җиткерү саваплы эш.

Әгъзам **ФӘЙЗРАХМАНОВ** туплады.

АЛИШ

Рафис КОРБАН

(Дәвамы. Башы 46, 47, 48, 49 нчы саннарда).

Үнөченче июльдә Алишка повестка килде. Ә Җәлилне җибәрмәделәр фронтка – опера театры аның Нәҗип Җиһанов белән берлектә язган «Алтынчәч» операсын куярга әзерләнә иде. Кызу репетицияләр бара. Җәлил эшне ташлап беркая да китә алмый, дип, аңа бронь бирделәр. Ә Алиш иртәгесен китәргә тиеш. Аны озатырга бөтен гаилә җыйналды. Энеләре Габдрахман белән Галимҗан Кызыл Армия сафларына 1939 елны ук алынган иде. Инде кайтыр вакытлары җитеп килгәндә, алар сугышны солдат булып каршылады. Менә абыйлары Абдуллага да чират җитте.

– Кызганыч, институтны тәмамлап булмады,– диде Алиш, үзен озатырга килүчеләргә.

– Сугыштан җиңеп кайткач бетерерсең, Алла боерса, – диде әнисе Газизә апа.

– Менә балаларны кем карар? Оркыя куна-төнә госпитальдән кайтып керми. Малайлар бик бәләкәй бит әле, – диде Рәбига апасы, сеңлесен кызганып.

– Борчылма, табармын берәр җаен. Әтиләре генә исән-сау әйләнеп кайтсын,– дип, Оркыя да үз чиратында ирен кайгыртырга уйлады. Алиш китәргә сорап гариза биреп кайткач, ул Карл Маркс урамындагы балалар йортына барып, малайларны шунда урнаштырырга сөйләшкән иде.

Озатырга килүчеләр төн уртасы җиткәндә, соң гына таралышты. Оркыяның әтисе Латыйп абзыйлар киткәндә таң ата башлаган иде инде.

Иртәгесен Алишны озатырга дусты Абдулла Әхмәт килеп җиткән. Алар өйдән чыкканда Әхмәт капка төбендә басып тора иде. Оркыя белән ике улы аны капка төбеннән генә озатып калды. Алар кочаклашып аерылышты. Алиш улларын күтәреп алып, бик озаклап кочагында тотты. Әхмәт аны Островский урамындагы сугышка китүчеләрне озату пунктына әйләнгән Мәдәният хезмәткәрләре йортына кадәр озатырга булды.

Бауман урамына җиткәндә аларга урамның теге башыннан килүче, иңенә биштәр аскан Фәрит Яруллин очрады.

– Син кая? – дип сорады Абдуллалар Фәрит дусларыннан.

– Сез барган җиргәдер инде, – диде Фәрит, елмаеп.

– Ничек алай? Нәҗип Җиһанов калган бит бронь белән. Җәлилгә дә бронь биргәннәр. «Алтынчәч»не чыгарасылары бар икән. Синең дә «Шүрәле»ңне чыгарырга репетицияләр бара иде түгелме соң? – диде Алиш.

– Кичектерелде «Шүрәле». Миннән башка гына чыгарырлар, кирәк дип тапсалар. Аның каравы «Кызыл Татарстан»ның кичәге санында безнең Муса белән язган «Соңгы көрәшкә» дигән җырыбызны бастырганнар.

– Шулаймыни? Ни арадаяздыгыз әле, өлгерләр дә инде үзегез?! Сезнең урыныгыз фронтта түгел, тылда. Менә шулай сугышчыларны көрәшкә рухландырган җырлар иҗат итәргә кирәк!

– «Шүрәле»не дөньяга чыгардык инде без аны Алиш абый белән, – диде шунда Фәрит. – Рәхмәт сиңа, Алиш абый.

– Шулай бугай шул, – дип исенә төшерде Әхмәт. - Күптән бит инде ул.

– Клавирын эшләп чыккач та, Алиш абый балет буенча тапшыру эшләде радиода.

– Фәрит үзе фортепьянода уйнап чыкты, – диде Алиш.

Утыз алтынчы елда халык дошманнарына каршы көрәш янә кабынып, утызынчы елда «Җидегән» төркемен оештыручыларның берсе дип танылган, радиокомитетта эшләп йөрүче Гадел Кутуй кабат эшеннән читләштерелгәч, аның урынына радиога Абдулла Алишны чакырганнар иде. Алиш менә шул вакытта оештырды Фәрит Яруллин белән аның «Шүрәле»се турында әңгәмә-концертны.

Озату пунктында повестка белән чакырылучыларны сафка тезеп, хәрби комиссар аларның бер ай дәвамында танк училищесы полигонында хәрби хәзерлек үтәргә тиешлекләрен әйтте. Училищеда кунарга урыннар җитешмәү сәбәпле, Казаннан китүчеләр хәрби өйрәнүләр вакытында өйләренә кайтып кунарга тиеш икән. Бу яңалыкка барыннан да бигрәк Фәрит сөенде. Чөнки аның хатыны корсаклы, бүген-иртәгә бала табам дип тора. Бүген дә мескен хатын, ирен ишегалларына чыгып, капка төбеннән генә елап озатып калды. Кичен кунарга өйгә кайтып керүен күргәч куаныр инде.

Занятиеләр беткәч өйгә кайтып кергән Алишны күреп, Оркыяның да шатлыгы эченә сыймады. Аннан да бигрәк малайлар сөенде. Инде кич җиткән дип тормады, Алиш улларын урамга алып чыгып китте. Гадәттәгечә, Черек Күл тирәли әйләнеп кайтырга булдылар. Повестка алган көнне генә йөреп кайтканнар иде әле югыйсә. Әллә тагын вакыт була, җай чыгып торганда бүген дә уллары белән булырга, күңелләрен күрергә уйлады.

– Әти, әкият сөйлә әле,– диде бәләкәй Айваз, урамга чыгуга ук.

– Кайсын сөйлим икән соң?

– Кайсынмы? Кырмыскалар турындагы әкиятне сөйлә...

Әкиятләре күп Алишның. Беренче әкиятен ул әле техникум тәмамлап, Минзәләдә мелиоратор булып эшләп йөргән көннәрендә язган иде. Бу утыз беренче ел иде. Алишка егерме өч яшьләр тирәсе. Минзәлә кантонының авыл хуҗалыгы бүлеге аны Хәбибә исемле бер апага фатирга урнаштырды. Көндез эшләп кайтада, кичен сукыр лампа яктысында әле китап укып утыра, әле күңеленә килгән уйларын дәфтәргә язып куя. Бала чакта аңа әтисе дә, әнисе дә әкиятләр сөйли торган иде. Ул әкиятләр аның күңеленә тирән сеңеп калган. Аннары әтисе укыган Тукай әкиятләре дә һич күңеленнән китми. Шулар тәэсирендә ул бәләкәй чагында ук үзе дә ниләрдер язгалый торган иде. Ә Минзәләдә, тыныч кичләрдә япа-ялгызы калып кич утырганда, үзенең күңеленә дә әкият язу уе килде. Бала чагында әтисе сөйләгән Капкорсак патша турында әкият сюжеты тынгы бирмәде аңа. Әтисе каяндыр укыган әкиятен сөйләгәндерме ул чакта, әллә үзе генә уйлап чыгарганмы, Алиш бу әкиятне бөтенләй башка сюжет белән, барысын да диярлек үзеннән чыгарып, өр-яңа детальләр өстәп язды. Язды да, кемгәдер укыйсы да килә бит инде. Хәбибә апаның Гомәр һәм Гали исемле ике улы бар. Шуларга укыргамы?

Шулай көннәрдән бер көнне Алиш эштән кайтып керсә, өйдә үзе белән бер яшьләрдә булыр, бер егет утыра. Читтә Хәбибә апаның әллә тагын бер улы булганмы? Шул кунакка кайтканмы?

– Таныш булыйк, мин Абдулла, – диде кунак егет.

– Бик әйбәт! Мин дә Абдулла! – диде Алиш. – Абдулла Алишев.

– Ә мин Усманов. Абдулла Усманов. Казаннан командировкага килгән идем. Кантон башкарма комитеты сөйләшеп, менә Хәбибә апага фатирга керттеләр.

– Ялгызыма күңелсез иде, бик әйбәт булды әле бу! Сөйләшеп утырырга иптәш булды.

– Мин дә өч ай буе нишләп кенә бетәрмен, дип кайгыра идем. Үзәк китапханәдән командировкага җибәрделәр мине.

Китапханәдән, дигәч, сөенде Алиш. Башка бер һөнәр иясе булса, көенер иде. Ә болай уртак темалар, уртак эшләр булырга мөмкин. Китапханә дигән оешма аның өчен бик якын бит ул. Алиш болай да буш вакытларында йә клубка, йә редакциягә, йә китапханәгә йөгерә иде. Ә хәзер аралашырга кеше табылды. Әкиятен дә шушы адашына укып чыгарга бик әйбәт булды әле. Ашап-эчеп, кич башкалар үз эшләре белән мәшгуль булып, Алиш адашы белән генә үз бүлмәләрендә калгач, ул аңа әкиятен укырга булды.

– Әгәр кешегә сөйләмәсәң, бер әйбер укыйм, – диде ул аңа.

– Менә тагын, кемгә сөйлим инде ике арадагы серне? – диде Абдулла.

– Сер түгел инде ул. Әкият. Мин сиңа бер әкият укымакчы булам.

– Әйдә соң, укы. Рәхәтләнеп тыңлыйм.

– Җайлап утыр, алайса, укыйм, – диде дә, Алиш өстәл тартмасыннан дәфтәрен алып сукыр лампа каршына килеп утырды һәм әкиятен укый башлады.

– «Капкорсак патша».

Әүвәл заманда, кәҗә команда, үгез адмирал, саескан сотник, тәлке шутник, үрдәк урәтник булган заманнарда бер патша яшәгән, ди. Аты – Капкорсак, кушаматы – Бушборчак булган, ди, бу патшаның. Кеше төсле үзе, үгезнеке төсле күзе, бүренеке кебек тешләре, нәкъ ерткычныкы кебек булган, ди, кылган эшләре.

Ул үзе Канкояр патшаның зур улы иде, ди...

Алиш бик дәртләнеп укый, Абдулла тын калып, игътибар белән тыңлый гына башлаган иде, бүлмәгә Хәбибә апа килеп керде.

– Мин әле бу, балалар. Танышырга да өлгермәделәр, күптән белешкән кешеләр кебек гәп тә корып җибәргәннәр. Нәрсә сөйләшәләр икән дип, кызыксынып кердем әле яныгызга, – диде хуҗа хатын.

– Менә Абдулла әкиятче икән бит. Әкиятен укый. Мин тыңлыйм, – диде яңа квартирант.

– Шулаймыни? Кара син аны, миңа да әйткәне юк. Әйдә, без дә тыңлыйк, тукта, Гомәр белән Галине дә дәшим,– диде дә, Хәбибә апа чыгып, улларын да чакырып керде.

Шулай итеп Алишка әкиятен барысына да берьюлы укырга туры килде. Сәгать буе утырсалар утырдылар, берсе дә ташлап чыгып китмәде, тын да алмый тыңладылар.

Казанга әйләнеп кайткач, Алиш «Капкорсак…»ны берничә тапкыр кабат эшләп чыкты. Әкиятне язучы дуслары да яратты. «Пионер каләме» журналында бастырып та чыгардылар. Шушы беренче әкиятеннән соң ук аның әкиятче дигән даны таралды. Бер даның чыккач, начар әкиятләр язып булмый икән шул. Аннары язган «Нечкәбил», «Койрыклар» әкиятләре дә бик ошады халыкка.

Аннан соң инде ул бик күп әкиятләр язды соңгы ун ел эчендә. Аларны «Пионер каләме»ндә, «Яшь сталинчы» гәзитендә, «Совет әдәбияты» журналында бастырып барды. Китап нәшриятында «Әкиятләр», «Ана әкиятләре» дигән китаплар чыгарды. «Сертотмас үрдәк» әкиятен пьеса итеп тә эшләде.

5.

Полигонда занятиеләрнең иртәнге сәгатьләрдә башлануы Алишка редакциягә кереп, инде бер тапкыр хушлашып киткән хезмәттәшләре белән кабат очрашып чыгарга да мөмкинлекләр бирде...

– Нәрсә булды, бронь бирделәрме әллә? – дигән сорау белән каршы алды пош-пош итеп авыр сулап ишектән килеп кергән Алишны күргәч, редактор Гомәр Хәбибуллин.

«Яшь сталинчы» белән «Пионер каләме» матбугат йортының икенче катында, бер-берсенә кара каршы урнашып, икесенә бер редактор иде.

(Дәвамы киләсе санда).

(Дәвамы. Башы 47-49 нчы саннарда).

Йолдызсыз калган 25 татар каһарманы

МИҢНЕӘХМӘТОВ КАСЫЙМ МИҢНЕӘХМӘТ УЛЫ

Миңнеәхмәтов Касыйм Миңнеәхмәт улы – 1922 елгы, Казанның Октябрь район комиссариаты аша озатылган. Кызыл байраклы 397 нче укчы дивизиянең артиллерия белән идарә взводында элемтәче булып хезмәт итә, кече сержант. 1945 елның 18 апрелендә Герой исеменә тәкъдим ителә, әмма Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

К.Миңнеәхмәтовны бүләкләү кәгазе.



Все графы заполнить полностью

Наградной лист

1. Фамилия, имя и отчество Минохметов Касим Минохметович
2. Звание Младший Сержант 3. Должность, часть Телефонист взвода управления Командующего артиллерией 397 Стрелкой Сарненской Краснознаменной ордена Кутузова дивизии

Представляется к присвоению звания „Героя Советского Союза"

4. Год рождения 1922 5. Национальность Татарин 6. Партийность Член ВКП/б/ с 1943 г. п/б № 6308548
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне (где, когда) Северо-западный, Брянский, I-й Украинский, I и 2-й Белорусский, 3 и I-й Прибалтийский, I-й Белорусский фронта с 25.2.1942 г.
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне Ранений и контузий не имеет
9. С какого времени в Красной Армии с июля 1941 10. Каким РВК призван Октябрьским Райвоенкоматом гор. Казань.
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) Медаль „За отвагу" пр. 397 СД № 06 от 9.8.1943 г., орден „Красная Звезда" пр. 397 СД № 058 от 3.12.1944 года.
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи

1. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

Младший Сержант Минохметов, работая надсмотрщиком связи взвода КАД при форсировании р. Одер в районе Хоен-Вуцов 18.4.45 г. первый проложил телефонную связь на западный берег реки. Прокладывая связь под сильным артиллерийско-минометным и пулеметным огнем противника тов. Минохметов переплывал реку вдоль разрушенного моста, цепляясь за быки моста.

Несмотря на сильный артиллерийско-минометный огонь противника тов. Минохметов, пренебрегая смертью продолжал прокладывать телефонную линию. Лодка, которая была приспособлена для форсирования водной преграды была разбита и это не остановило стремления тов. Минохметова вплавь выполнить боевую задачу в столь ответственный момент.

За геройский подвиг младший сержант тов. Минохметов заслуживает высшей Правительственной награды-присвоения звания „Героя Советского Союза"

Начальник Штаба Артиллерии дивизии
18.4.45 г. Майор /Науменко/

Ходатайствую о присвоении звания „Героя Советского Союза"

Командующий артиллерией
397 Стр. Сарненской Краснознаменной
ордена Кутузова дивизии
полковник /Булатов/

"18" апреля 1945 года.

Командир (начальник) ______ (звание)

«___» ______ 194__ г.

МИҢЛЕБАЕВ МӘКЪСУТ МИҢЛЕБАЙ УЛЫ

Миңлебаев Мәкъсут Миңлебай улы – 1923 елгы, Октябрь район комиссариаты аша озатылган. 57 нче гвардия укчы дивизиясенең 170 полкында пулеметчылар отделениесе командиры, гвардия кече сержанты. 1944 елның 4 августында Герой исеменә тәкъдим ителә, тик Кызыл Байрак ордены белән генә бүләкләнә.

М.Миңлебаевның бүләкләнү кәгазе.



НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя, отчество
2. Звание 3. Должность и часть
Представляется к
4. Год рождения 5. Национальность
6. Партийность беспартийный 7. Участие в гражданской войне и последних боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне (когда, где)
8. Имеет ли ранения или контузии
9. С какого года в Красной Армии
10. Каким РВК призван
11. Чем ранее награжден Медаль „За отвагу"
12. Постоянный домашний адрес представленого к награждению и адрес его семьи

Краткое конкретное изложение
ЛИЧНОГО БОЕВОГО ПОДВИГА:

Бесстрашный пулеметчик гвардии мл. сержант МЕНИБАЕВ М.М. участник отечественной войны с 1943 года. Стойко и самоотверженно сражался на разных участках фронта, освобождая родину от немецких захватчиков.

При форсировании р. Висла 1.08.44г. т. МЕНИБАЕВ первым переправился на левый берег и огнем из своего пулемета высадку и атаку вражеской обороны. В этом бою т. МЕНИБАЕВ уничтожил три огневых точки пр-ка в том числе один крупнокалиберный пулемет и до 15 гитлеровцев.

В дальнейших боях по расширению плацдарма т. МЕНИБАЕВ выдвигая свой пулемет на выгодные позиции всемерно содействовал продвижению пехоты, меняя огневые позиции он был неуязвим для противника.

За личный героизм гвардии мл. сержант МЕНИБАЕВ достоин правительственной награды " ГЕРОЙ СОВЕТСКОГО СОЮЗА "

Командир 170 гв. стр. полка
гвардии подполковник /ДРОНОВ/

4.08.1944 года.

ХӘБИБУЛЛИН МИНҺАҖ ХӘБИБУЛЛА УЛЫ

Хәбибуллин Минһаҗ Хәбибулла улы – 1910 елда Әлки районында туган, Самара өлкәсенең Чардаклы район комиссариаты аша фронтка озатылган. 5 нче гвардия армиясендә 9 нчы гвардия һава десанты дивизиясендә 28 нче һава десанты-укчылар полкында укчылар батальоны командиры, гвардия капитаны. 1945 елның 25 февралендә Герой исеменә тәкъдим ителә, Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

ХАҖИЕВ ЗИННУР ГАЗИ УЛЫ

Хаҗиев Зиннур Гази улы – 1918 елда Мамадыш районының Уразбакты авылында туган, шул район комиссариаты аша фронтка озатылган. 1 нче Украин фронтындагы 13 нче армиянең 172 нче укчы дивизия составындагы 747 нче полкта отделение командиры була, сержант дәрәҗәсендә. 1945 елның 2 маенда Герой исеменә тәкъдим ителә, әмма Кызыл Байрак ордены белән генә бүләкләнә. 1991 елда вафат булгач, туган авылы Уразбакты зиратында җирләнә.

ХӘНӘФИЕВ ШӘМСИ

Хәнәфиев Шәмси – 1914 елгы, Ютазы район комиссариаты аша фронтка озатылган. 13 нче гвардия механикалаштырылган бригада составындагы укчылар ротасы командиры була, гвардия лейтенанты. 1944 елның 28 августында Герой исеменә тәкъдим ителә, тик фәкать 3 нче дәрәҗәдәге Суворов ордены белән генә бүләкләнә.

(Дәвамы киләсе санда).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.

«Миллиард татар» челтәреннән. **Вахит ИМАМОВ** тәрҗемәсе.

НАИЛӘ ГӘРӘЕВА –

Журналист Раил Садретдинов Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Наилә Хәким кызы Гәрәева белән әлеге әңгәмәне, Татарстан радиосы өчен, актриса үзенең 80 яшьлек юбилеена әзерләнгән көннәрдә, 2020 елның ноябрендә яздырган. Аны газета укучыларыбызга да тәкъдим итәбез.

Паспорттагы саннар һәм күңел яше

– Наилә апа, сезнең кебек актрисалар, гадәттә, яшьләрен яшерергә тырыша.

– Яшермим. Шушы кадәр гомер – Аллаһы Тәгаләнең миңа бүләге ул. Паспорттагы яшькә карамыйча, «күңелем белән яшь» дип йөргән кешеләрне аңламыйм. Мин һәр көнне үземә ничә яшь икәнне белеп уянам, шөкерана кылам. Бу яшькә җитүемә бик гаҗәпләнәм, бу – бик зур бәхет.

– Русларда Сезнең кебек шәхесләр турында «Человек-эпоха» диләр. Үзегезне дә шулай дип саныйсызмы?

– Мин чынлап та үземне хәзер дә совет заманы кешесе итеп хис итәм. Мин ул чорны бик искә төшерәм. Ул – минем балачагым. Заманында хөкүмәт тарафыннан бик күп бүләкләр алдым – «Артек»та булдым, Чехословакиягә барып кайттым. Бөтен җирдә бушка – мәктәпләр дә, түгәрәкләр дә. Пионерлар сараенда бөтен түгәрәкләрне йөреп чыктым. Артистлык сәләтем шунда ачылды. Ул вакытта радиога да чакыралар иде. Русча «Пионерская зорька» дигән тапшыруны башлап җибәрә идем. Гомумән, радио миңа бик якын. Минем анда шактый гомерем узды. Балачакта, артистка булгач та, төннәр буе калып эшли, шактый тапшырулар әзерли идек. Радио белән яшәдек. Мин әле дә иртән торам да «Татарстан» радиосын кабызам. Ул миңа бик якын.

– Бүген бөтен нәрсә түләүле булуга, акчага корылуга сезнең мөнәсәбәт нинди?

– Дөнья гел үзгәреп тора, ләкин мин күңелем белән «теге дөнья» (совет заманы) кешесе. Бу заманда яшәү бик кыен. Яшьләргә үзләре булып калырга, үз урыннарын табарга, югалмаска авыр. Күбрәк яшьләр өчен борчылам. Оныгым да (Йосыф Бикчәнтәев) театр юлыннан китте. Аның өчен дә борчылам.

– Театр яшьләренә сез нинди мөнәсәбәттә?

– Бик әйбәт мөнәсәбәттә. Алар көн-төн театрда. Аларга яшәве бик авыр – гаиләләре, балалары бар. Аларны да сакларга кирәк. Театр – ул килеп эшләп, уйнап китү генә түгел, анда яшәргә кирәк. Шуңа күрә күп вакыт алар монда балаларын да алып килә, гомерләре театрда уза. Яшьләр килгәч, театр яши, дигән сүз. Мин аларга бик сокланам һәм шатланам. Уйлап кына карагыз, безнең заман кешеләренең бөтенесенең – бер генә бала. Әле аны да карарга вакыт юк иде. Безнең балалар барысы да театрда үсте. Яшьләр башка төрлерәк, аларга заманага җайлашу бик авыр. Алар күбрәк үзләренә бикләнгән. Әмма безнең театрда яшьләр бик тату, дус яши. Театрның мохитен, илһамын билгеләп торалар.

– Сез озак еллар Казан театр училищесында, соңрак мәдәният институтында да укыттыгыз. Бүген үзегез янында эшләгән укучыларыгыздан кемнәр бар?

– Иң сөендергәне – укыткан студентларымның, төпләнеп, бер эштә эшләүләре. Аларның исемнәрен ишетсәм дә шатланам. Безнең театрда үзем укыткан Венера (Афият) Шакирова, Фәрит Бикчәнтәев эшли. Марсель Хәкимович театр училищесына Илдар Хәйруллин белән икебезне үзенең ассистенты итеп алгач, укыткан беренче төркем студентларым. Ул вакытта театрда рольләрем азрак иде. Марсель Хәкимович, булышу йөзеннән, үзенә ярдәмче итеп чакырды. Аннары соң университетка кереп киттем, анда да укыта башладым. Театрда тагын Камил Камал бар иде, иртә китеп барды. Бик сәләтле артист иде. Данил Салихов та – беренче студентларымнан. Минзәлә, Оренбург театрларында да шәкертләрем бар.

– Марсель Сәлимҗанов исемен телгә алдыгыз. Ул – сезнең тормышта зур роль уйнаган шәхесләрнең берсе. Тагын шундый кемнәрне атый аласыз?

– Кеше үз язмышын үзе генә хәл итми, аның тирәсендә булган кешеләр дә зур йогынты ясый. Язмышымны хәл иткән иң беренче кеше – Шириздан абый Сарымсаков иде. Заманында Камал театрының баш режиссеры. Мин рус мохитендә үстем. Татар мәктәпләре юк, рус мәктәбендә укыдым. Качалов театры каршында театр студиясе ачылды. Анда бер төркем – руслар, икенчесе – татарлар иде. Мин документларымны рус төркеменә тапшырдым. Укырга керүчеләр исемлегеннән үз исемемне эзләп торганда, арттан бер ир тавышы: «Сез татар кызымы?» – ди. «Әйе», дим. «Ә нишләп сез рус төркеменә керәсез?» – дип сорый. «Татарча чамалы гына беләм, русча күбрәк», дим. «Өйрәнерсез. Сезнең киләчәгегез, сезнең тормышыгыз – татар театрында», диде. Уйлап кына карагыз әле, ул бит, пәйгамбәр кебек, минем язмышымны хәл итте. Мин татар төркемендә укып бетердем. Шириздан абый, баш режиссер буларак, мине шактый спектакльләргә алды. Ул китеп баргач, бернечә елдан театрга Марсель Сәлимҗанов килде. 1960 елда, икенче курста укыганда, Рәфкать Бикчәнтәев мине «Беренче мәхәббәт» спектакленә алды. Ул да минем өчен үзе бер зур бәхет булды. Ул вакытта татар театрында яшьләр юк иде. Мәскәүдән щепкинчылар укып кайтмаган. Шуңа күрә сәхнәдә уйнаган беренче ролем буларак та, әле кем белән диген, Шәүкәт ага Биктимеров белән бит ул, беренче спектакле буларак режиссер Рәфкать Бикчәнтәев һәм драматург Хәй Вахит өчен беренче әсәре сәхнәдә куелу уңаеннан да зур вакыйга булды. Шунда да кешеләрнең яхшы мөнәсәбәте, игътибарыннан миңа бәхет елмайды.

Аннары соң Рәфкать Бикчәнтәев белән дуслашып китеп, мин аның хәләл җефете булдым. Балабыз Фәрит туды. Хәзер инде ул – әтисенең юлын дәвам итүче. Бу үзе могҗиза түгелме?! Без театрда эшли башлаганда, Фатыйма апа Ильская, Фоат Халитов, Фатыйх Колбарисов, Гәүһәр апа Камалова, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Мәрзия апа Миңнебаева, берара директор булып алган, миңа «Гүзәлем Әсәл» спектаклендә роль биреп, язмышыма зур йогынты ясаган кеше – Рәшидә апа Җиһаншина кебек олы шәхесләр эшли иде. Без бит алар белән бер сәхнәдә уйнап, үзебезгә күп белем, гыйбрәт алдык, алар белән бергә театрда яшәдек. Алар безне шундый якын итә, бик аралаша иде, һәрчак булышып тордылар. Булышмасалар да, аларга карап тору гына да үзе бер мәктәп иде.

– Сез үскән чорны хәзер урбанистлар «Казань деревянная» дип атый. Сез үскән Подлужная урамы танып булмаслык булып үзгәрде. Иске, тарихи биналарның сүтелүенә мөнәсәбәтегез ничек?

– Мин иске Казанны яратам һәм сагынам. Хәзер күп нәрсә туристлар өчен эшләнә. Элеккеге тарихи биналар миңа бик кадерле. Казанның тыныч вакытларын сагынам.

– Подлужная урамына сезнең гаилә ничек килеп төпләнгән?

– Минем әти – хәрби кеше, НКВДда эшләде. Безгә шул урамда ике катлы агач йортның беренче катында 2 бүлмәле бер фатир бирделәр. Менә шунда башта абыем, аннары апам, аннары мин туганмын. Подлужная урамы – гаҗәеп җир. Үзе шәһәр уртасында булса да, нәкъ авыл урамы кебек. Анда ат йөри, әтәчләр кычкыра, сыерлар мөгри иде. Ишегалдындагы күршеләр белән бик аралаша, дус булдык. Төрле кичәләр, бөтен бәйрәмнәрне бергә уздыра идек. Урамдагы бөтен балаларны белеп үстек. Абыем белән утын кистек. Мин бер кәлимә рус сүзен белмәгән, гел татарча гына сөйләшкән дәү әни белән үстем. Ул гел тәсбих тарта, намаз укый иде. Безне шул тәрбияләде. Өйдә татар мохите булды, гәрчә әни гел: «Өйдә русча сөйләшегез», – дип әйтә килде.

Подлужная урамында башта агач мәктәп иде, аннары таш мәктәп салдылар. Мин 7 нче сыйныфка кадәр шунда укыдым. Мәктәптә бик актив булдым, бөтен бәйрәмнәрне оештыра, катнаша идем. Шулай артистка булып киттем. Әни – бик зәвыклы кеше. Әлләни белеме булмаса да, эчтәге рухы бик бай иде. Минем әни матурлык дигән әйбергә мөкиббән кеше. Өйдә бөтен нәрсә матур иде. Ул киемнәрне үзе тегә – беренче имтиханга барганда, ул теккән күлмәктән, аның түфлиләрен киеп

СОҢГЫ ИНТЕРВЬЮ

Михаил Захаров фотосы / «Татар-информ»

бардым. Бер толым чәч кенә үземнеке иде (көлә). Әни театрга кереп актриса булуыма бик шатланды. Әти бик матур җырлый. Аны, еш кына, артистлар мәҗлесләргә дә чакыра иде. Ул Салих Сәйдәшев, Хәким Сәлимҗанов белән дус булды. Бернәрсә дә тиктомалдан булмый бит ул. Һәрбер нәрсәнең нигезе була. Хәтерлим, өйдә китаплар бик күп иде. Без дәрес әзерли торган өстәл өстендә композиторлар, язучылар, шагыйрьләрнең плакатлары эленеп торды. Аларның исемнәрен, шигырьләрен белеп үстек, шулай тәрбияләндек. Рус мохите чолганышында яшәсәк тә, өйдә татарлык сакланды. Дәү әни ул яктан бик игътибарлы иде. Аның абыйсы – Казанда беренче хаҗга барган Әхмәтҗан хәзрәт, ул мәчеттә эшләде. Дәү әни Чаллы ягындагы бер авылда яшәгән, аның ире – азәрбайҗан. Минем әни – Кадыйр кызы Рауван. Ул азәрбайҗан исеме. Бабай исем кушкан да, үлеп тә киткән. Ул үлгәч, дәү әниемнең абыйсы әнием белән икесен Казанга алып кайткан. Алар Тукай урамында яшәде. Шуңа күрә әни дә Казан кызы кебек иде. Шәһәр кызы дигәннән, театрда эшли башлагач та моны күп ишетергә туры килде, чөнки чын татарлар авылдан чыга, дип саналды.

– Әти яклап әби-бабай кайсы яктан иде?

– Әти – Арча ягыннан. Мәскәүдә хәрби академия тәмамлаган кеше. Татар әдәбиятын белә, укымышлы, сәнгатьне аңлаган, гаделлекне яраткан кеше иде. Аның әти-әнисе иртә китеп барган, мин алар белән аралаша алмадым. Әти сугышның башыннан ахырына кадәр катнашты, бик соң гына инвалид булып кайтты һәм 1953 елда үлеп китте. Әти – аз сүзле, эшкә бирелгән кеше иде. Гел хәрби формадан йөрде. Без аны күрми дә диярлек идек. Аның мине бер тапкыр музыка мәктәбенә алып барганы гына истә. Әни өчебезне дә музыка мәктәбендә укытты. Абыем – музыкант, скрипач булды. Гомере буе симфоник оркестрда, Натан Рахлин белән эшләде. Ул чын музыкант иде. Апам фортепиано классында 4 ел гына укыды, язмышын музыка белән бәйләмәде. Мин, абыем кебек, скрипка классын тәмамладым. Музыкант буларак ул миңа бик ярдәм итте һәм Фәриткә дә аның йогынтысы зур булды. Ул аның концертларына йөреп үсте. Фәрит музыканы аңлый, күп спектакльләрен музыкаль яктан үзе бизи. Фәритне, гастрольләрдә йөреп, музыка мәктәбендә укыта алмасак да, оныгым Йосыфны 5 яшьтән музыка мәктәбенә бирдем. Хәзер музыка белән бик тә мавыга.

Еллар һәм рольләр

– Театрда эшли башлагач, «шәһәр кызы» дигән сүзләр күңелегезгә тия идеме?

– Элек игътибар бирми идем, аннан сизелде. Артистларның күбесе авыл мохитендә үскән. «Әни килде» спектаклендә Ана роле Марсель Хәкимовичның миңа соңгы бүләге булды. Ярты театр каршы иде. «Нинди ана инде ул? Ул бит – шәһәр хатыны. Үзе дә, тавышы да яшь», – диделәр. Әлбәттә, Галимә апа Ибраһимовадан соң бу рольгә алыну миңа да авыр булды. Үзем дә каршы килеп маташтым, әзер түгел идем. Марсель Хәкимович: «Син уйныйсың! Ә оныгыңны Йосыф уйный!» – диде. Мин: «Анда бит кыз бала», – дим. «Ир бала булачак!» – диде. Белмим, ничек ышандырып тапшыргандыр ул бу рольне, бүгенгә кадәр аны зур вакыйга итеп кабул итәм. Иң беренче куелышта мин бит киленне уйнаган идем. Ана ролен башкарган Галимә апаның тавышы шул вакыттан колагымда сакланып калган. Ана булып сәхнәгә чыкканда сизәм: тамашачы кабул итми. Икенче пәрдәгә чыкканда: «Хәзер кемлегемне күрсәтәм мин сезгә», – дим. Шактый драматик вакыйгаларга бай пәрдә. Тирән кичерешләрне бирә алдым. Халык кул чапты, кабул итте. Авырлык белән булса да ул рольгә килдем һәм җиңдем. Әле бүгенгә кадәр бөтен сүзләрен хәтерлим бу ролемнең. Ул минем белән бергә яши. Марсель Хәкимович берара рольләр бирми башлаган иде, 10 еллап рольләрем булмады. «Әни килде»дәге Ана роле белән ул барысын да аклады. Театрда уйнауга караганда уйнамаган вакытлар бик кадерле һәм авыр була. Ул вакытта син аңлыйсың: театрны яратасыңмы, әллә үзеңнеме. Әгәр дә син үзеңне генә яратсаң, син театрдан китә дә аласың. Әгәр дә син театрны яратсаң, син бервакытта да, нинди генә авыр вакытлар булмасын, театрны ташлап китә алмыйсың. Мин ул нәрсәгә инандым.

– Роль бирмәгәч, Марсель Хәкимовичка үпкәли идегезме?

– Юк. Ничек үпкәлим? Мин аны миңа туры килми торган рольләр дип саный идем. Анда яшьләр өлгереп җитте. Урта яшьләр – тормышта да, сәхнәдә дә иң авыр вакыт. Яшь чакта сине өмет яшәтә, ә урта яшьләрдә уйлана, үз гамәлләреңә бәя бирә, йомгак ясый башлыйсың. Театрда уйнамый тору бик авыр. Русларда бик акыллы сүзләр бар: «В театре самая необходимая вещь – это культура страдания». Ул вакытта бик сыналасың: дөрес киттеңме ул юлдан, чынлап та яратасыңмы син театрны? Ул – зур сынау. Шул вакытта театрга Фәрит килде. Беренче тапкыр «Бичура» спектаклендә балаларын эзли торган карчыкны уйнадым. Ул бик зур тарихи вакыйга булды. Ул вакытта «авыл бетә» дигән сүзләр, спектакльләр юк иде. Минем тәкъдим буенча Фәритнең шул спектакльгә алынуы – үзе бер батырлык һәм кыюлык сорый иде. Ул рольне бик яратып эшләдем. Аннары «Хушыгыз» спектаклендә Миләүшә ролем булды. Ул – минем урта яшьләрдә уйнаган төп эшем, үземне артистка буларак яңадан сынап караган, шуңа инанган чагым. Тормышта урта яшьләрдә килгән барлык борчулар тупланган иде шушы рольдә.

– Наилә апа, сез – режиссер хатыны. Актриса. Режиссер әнисе һәм артисткага кайнана. Сезгә кайсы булу кыен?

– Ана булу кыен. Фәрит өчен бик борчылам да, шатланам да. Ул эштә иң кирәк әйбер – батырлык һәм кыюлык, чөнки уңышлымы, түгелме икәнен бервакытта да алдан ук әйтеп булмый. Хәзер милләтнең төп үзәге – театр, чөнки тамашачы, бирегә килеп, иң беренче чиратта үзенең татар икәнлеген таный, үзен борчыган сорауларга җавап таба. Театр милләт өчен зур эш башкара. Фестивальләр, конкурслар хәзер бик күп, аларның кадере бөтенләй бетеп бара. Ә театр әле төп бурычын үти – милләтне берләштереп тора, телне саклый. Хәзер театр барыбер икенче төрле: хәрәкәткә корылган, кешене күбрәк тышкы яктан кызыктыра. Ә без – төп урында эчке халәт булган, психологик театрда яшәгән артистлар. Әмма миллилекне әле саклый. Театрыбызны бөтен дөньяда таныйлар, беләләр, кабул итәләр.

– Шушы яшьтә дә тамашачы алдында, сәхнәдә булу – зур бәхеттер?

– Бәхет ул, әмма сәхнәгә чыгу бик дулкынландыра. Гомереңнең актык көннәренә кадәр сәхнәдә «Әлдермештән Әлмәндәр»не уйнаган Шәүкәт абыйның: «Нишләп шулкадәр борчылам соң? Элек сәхнәгә бик җиңел чыга идем», – дигән сүзләре искә төшә. Мин катнашкан спектакльләр сирәк уйнала. Ай буе син аны көтеп торасың, ә бит син формада булырга тиеш, шуңа күрә күбрәк дулкынланасың, борчыласың. Сәхнә бит ул – үзе бер сихерле дөнья. Анда чыккач, бөтен нәрсә, борчуларың-мәшәкатьләрең онытыла, бөтенләй икенче дөньяда яшәгән кебек, яшеңне дә, күптән уйнамаганыңны да онытасың. Сәхнә серләре, могҗизасы мине әле саклый, Аллага шөкер…

– Әңгәмәбезгә йомгак ясап, шуны сорыйсым килә: «Язмышыма рәхмәт, тормышымнан канәгатьмен», – дип әйтә аласызмы?

– Үкенечле нәрсәләр тормышта шактый булды. Күп нәрсә кешенең үзеннән тора. Һәрхәлдә, көчемнән килгән нәрсәне эшләдем – үзем сайлаган юлыма тугрылыклы булдым, бала үстердем. Бу – үзе зур бәхет, кешенең төп вазыйфасы шул. Хәзер инде оныгым да үсеп җитте, Аллага шөкер. Бөтен нәрсә дә Аллаһы Тәгалә хозурында, мин шулай кабул итәм.

intertat.tatar.

Мәдәни җомга
22 декабрь
№50, 2023

ГЕНЕРАЛ

(Дәвамы. Башы 48, 49 нчы саннарда).

Сугыш тәмамлангач, байтак тарихчылар Ефремов армиясенең тар-мар ителүендә Жуковны гаепли. Бөтенләй үк нигезсез дә түгелдер, чөнки Жуков Ефремов карамагындагы 9 нчы гвардия укчы дивизиясен үзенең резервына чакыртып ала. Март аенда бу дивизия 43 нче армиягә ярдәмгә озатыла. Ефремов карамагында генерал Эрастов командалыгындагы 93 нче дивизия генә берникадәр вакыт таянырлык була. Ләкин бер дивизиягә таянып кына, әлбәттә, тулы бер армияне коткарып булмый. Чигенүләр башлангач, Ефремов Генштабка мөрәҗәгать итеп, армияне Угра елгасы буйлап чолганыштан алып чыгарга рөхсәт сорап карый. Ә югарыдан маршал Шапошников баш өстеннән сикергән Жуков фәрманы яңгырый: «Ә мин Киров шәһәрчегенә таба чигенсәң, анда партизаннар ярдәменә таяну отышлырак булачак, дип саныйм». Сталин шәхсән үзе: «Ефремов – тәҗрибәле командарм, аның фикере белән ризалашырга кирәк», – дип әйтеп карый да бит, аңа кушылмыйлар... Шулай да, армия башлыгының хәвефле хәлдә калуын төшенеп, аны коткару өчен Мәскәүдән «капчык» эченә махсус самолет юллыйлар. Ләкин генерал Ефремов очучы алып килгән боерыкны үтәүдән баш тарта: «Солдатларыма нинди тәкъдир язган булса, миңа да шул. Ә менә армия һәм дивизия байракларын Олы Җиргә кайтарып бирсәң иде»...

Моңа бөтенләй капма-каршы мисаллар да була. Сугыш барышында, нәкъ шушы рәвешчә үк чолганышта калган яралы солдатларны алырга дип санитар самолет килеп төшкәч, 338 нче укчы дивизиянең штаб башлыгы полковник Яков Тетушкин яралыларны тирә-юньгә чәчеп, кабинага үзе менеп утыра һәм чолганыштан шул юл белән кача. Шушы мисал белән Ефремов каһарманлыгын һич кенә дә яңәшә куеп булмый!..

33 нче армия белән элемтә 13 апрельдә тулысынча өзелә. 15 апрельдә 50 нче армия белән кушылу өчен ике чакрым арада коридор ясарга тырышып карыйлар, дошман аларның бу ниятен дә өзә. Коточкыч басымга түзмичә, армия вак төркемнәргә таркалып бетә. Ефремов төркемендәгеләр партизаннар белән бәйләнешкә керергә, алар ярдәмендә камалыштан чыгарга омтыла. Ләкин иң тугры булып кыйланган ялчылар арасында икейөзле, хыянәтче җаннар да табыла шул. Армиянең баш хирургы Исаак Жоров истәлекләрендә язып калдырганча, армиянең элемтә башлыгы полковник Николай Ушаков хыянәтче булып чыга һәм нәкъ менә шул кеше составында генерал Ефремов та булган һәм чигенеп барган төркемне «партизаннар» ягына алып чыга. Ә «партизаннар» үзләрен көтеп торучы яңа бер «төркем» белән очрашуга барганда, алар арасындагы бер сугышчы 33 нче армиянең дәүләт куркынычсызлыгы капитаны Давид Камбургка хыянәтчеләрнең Ефремовны эләктереп, дошман ягына чыгарга ниятләве турында ачып сала. Капитан Камбург хыянәтче Ушаковны шундук атып үтерә. Ефремовчылар Угра елгасы буйлап янә көнчыгышка таба юл ала. Ләкин ул якта да дошман чылбырын өзеп чыгарга кирәк бит. Хыянәтче Ушаков кемнәрдер аша хәбәр озатып өлгергәндер, дошман чылбыры ефремовчыларны ут ачып каршылый. Соңыннан ачыклангавча, командарм ярдәмчеләрен хыянәтче Ушаков хәбәр итеп куйган немецларның «Бранденбург-800» атлы махсус подразделение төркеме озата бара. Шулар белән яу барышында Ефремов берничә тапкыр яралана. Генералны агачлардан ясалган носилкада күтәреп бара башлыйлар, 18 апрельдә тагын немец разведкасы пәйда булгач, Ефремов әүвәл яныашәдә барган һәм армияда медицина инструкторы булып хезмәт иткән хатынын атып үтерә, аннары көпшәне үзенең йөрәгенә төби... Ефремов белән бер төркемдә чигенеп барган генерал-майор, 33 нче армиянең артиллерия башлыгы П.Н.Афанасьев һәм асылда барча армия штабы әгъзалары дошман белән бәрелештә һәлак була...

Ставкага мондый күңелсез хәбәрләр кайчан килеп ишетелгәндер, анысы мәгълүм түгел. Ә Вермахтның коры җир гаскәрләрендә штаб башлыгы булып торган генерал Ф.Гальдер 16 апрельдә үз көндәлегенә «Русларның 33 нче армиясы юкка чыгарылды», дип язып куя инде...

Без югарыда телгә алган капитан Камбургны сугыштан соң берничә оешма да эзләп таба алмый. Тагын да сәерррәге: Ефремов янында баш хирург булып йөргән Исаак Соломонович Жоров әсирлеккә эләгә, аны берничә җәзага да тартмыйлар, ул бер ел буе концлагерьда түгел, ә хәрби госпитальда табиб булып эшли. Һәм шушы шома балык нинди юл беләндер 1943 елның мартында партизаннар ягына качып чыга. Сәер табиб 1976 елга кадәр гомер итә әле... Ә Ефремов төркеменнән армияда хәрби юрист саналган Александр Зельфа гына исән кала. Аннан берничә тапкыр сорау алалар, ләкин бер җинаять та тагып куя алмыйлар...

Генерал Ефремовны җирләү тарихы да һичкем язмышына да охшамаган. Носилкада яткан Ефремов гәүдәсен немец солдатлары эзләп таба һәм Вязьманы саклап торучы генерал Артур Шмидт каршына алып кайта. Ата нацист булган Шмидт совет генералының хәтта беләгендәге алтын сәгатенә дә тидерттерми һәм, кабер казыткач, немец солдатлары белән совет әсирләренә кабернең ике ягына тезелешеп басарга әмер бирә. Артур Шмидт үз истәлекләрендә әлеге вакыйганы шул рәвешчә сурәтли: «Рус солдатлары үз генералларының гәүдәсен берничә чакрым буе ясалма носилкаларга салып кайта. Генералның һичбер документы булмаса да, мин аны шәһәр үзәгендә җирләргә карар кылдым. Каберне рус әсирләре һәм шәһәр кешеләре казыгач, генералның гәүдәсен шуның янына куеп, берничә сүз әйттем. Фюрерның җиңелү белмәс армиясы дошманнарының каһарманлыгын да хөрмәт итә белә, дидем. Аннары вермахт солдатларына текәлеп, Ефремов Россия өчен ничек сугышкан булса, сез дә Германия өчен шулай сугышыгыз, дип мөрәҗәгать иттем. Минем фәрманым буенча, кабер өстенә дә немец һәм рус телләрендә язылган табличка куелды».

Артур Шмидт Вязьмадан соң Сталинград өчен барган сугышка китә. Анда фельдмаршал Фридрих Паулюс җитәкләгән 6 нчы армияның штаб башлыгы вазыйфасын башкара. 1943 елның февралендә Паулюс белән бергә совет гаскәрләренә әсирлеккә бирелә. Аның генерал Ефремовны җирләвен белеп алуга ук, махсус самолет белән НКВД карамагына, Мәскәүгә алып кайталар. Аннан Ефремовның сатлыкҗан иконлеген әйттерәсе借ләре килсә дә, немец генералы сынмый. 1955 елга кадәр Шмидт совет әсирлегендә тотыла. Паулюс – хатыны белән очраштыру вәгъдәсенә ышанып, Нюрнберг судында совет яклы булып чыгыш ясаса да, Шмидт үз ватанына хыянәт итми. Ул 1987 елның 5 октябрендә Германиянең Карлсруэ шәһәрендә вафат була...

Ржев белән Вязьма калалары өчен сугыш шушының белән тәмам булган икән, дип йомгаклап куярга берүк ашыкмагыз. Әле 1942 елның апрель ае гына тәмамланып килә, ә без атаган ике кала да һаман булса дошман кулында бит. Вязьма турында мәгълүмәтне әйттек, инде Ржев «кала»сының шул яздагы хәлен бәян итик. Элеккеге 5 меңгә якын хуҗалыктан Ржевта 300 ләп чамасы гына кирпеч йорт исән калган, фашист баскыннары шәһәр халкын тулысынча диярлек кырып бетергән. Саклардай да, талардай да һичбер байлыгы юк. Ләкин шушы Ржев «хәнҗәрендә» Гитлер штабы һаман 700 меңгә якын сугышчысын тота. Сталин Ставкасы да Калинин фронтында бер миллионлы гаскәр туплап куярга мәҗбүр була.

Май ае буе, канга баткан яраларын ялап сүл җыючы җанвар төсле, ике як та тып-тын гына тора. Ржев белән Гжатск калаларын азат итмәкче булып, совет ягы 1942 елның июнендә элек чолганыштан чыгу буенча «тәҗрибә туплаган» һәм, билгеле ки, өр-яңадан тулыландырылган 39 нчы армияне һөҗүмгә ташлап карый. Ләкин санаулы көннәрдән соң ук аны немец генералы Модель дивизияләре чолганышка ала. Шушы һөҗүм барышында гына да совет армиясе 47 мең сугышчы югалта...

Гитлерның Сталинградка төбәп һөҗүм башлавын төшенеп алуга ук, немец гаскәрләрен ул тарафка җибәрмичә тотып тору өчен, август аенда янә бер мәртәбә атакага ташланып карыйлар. 1942 елның 28 июлендә генә «бөек» Сталинның 227 номерлы, «бер адым да артка чигенмәскә» өндәгән «өр-яңа» бер фәрманы пәйда була. Окобын ташлап чигенгән совет сугышчыларын алга куу яки атып үтерү өчен тыю (заградительный) отрядлар төзелә һәм яуда җебегәнлек күрсәткән солдатларны штраф роталарына озату башлана. Гаҗәпкә калдырырлык хакыйкатьләр дә бар бит: соңыннан Советлар Союзы Герое һәм атаклы язучы булып танылачак В.Карповка биш ай буе штрафбатта «гөнаһын юарга» туры килә. Татар уллары арасыннан берденбер булып армия генералы дәрәҗәсенә ирешәчәк Мәхмүт Гәрәев та нәкъ менә шушы Ржев каласы өчен сугышларда хәрби юлын башлый...

23 августта совет гаскәрләре Зубцово, Карманово пунктларын азат итә. 30 нчы номерлы армия Ржевны яулау өчен алга ыргыла, ләкин Полунино авылы янында каты чикләвектәй оборона сызыгына җиткәч, яр күреп сөрлеккән ат шикелле, капылт туктап кала. Ике як та йөзәрләгән танкларын һөҗүмгә ташлый. Бер айга сузылган канлы бәрелешләрдән соң гына совет гаскәрләре әлеге авылны азат итүгә ирешә һәм 21 сентябрьдә Ржев янындагы бистәләргә дә үтеп керә. Ләкин Ржевны яулый алмыйча кире чигенәләр. Полунино авылында 12 мең кызылармеец җирләнгән «туганнар кабере» калкып чыга...

Ноябрь аенда безнекеләр тагын бер мәртәбә Ржевны



● **Генерал-лейтенант М.Ефремовны җирләү.** (clck.ru/ejGf5)

ЕФРЕМОВ ФАҖИГАСЕ

В.Имамов фотосы.

● **Немец генералы Артур Шмидт** (clck.ru/ejGrf)

азат итәргә талпынып карый. Шәһәргә һөҗүм итү һәм Модельнең 9 нчы армиясен чолганышка эләктерү өчен 15 дивизия туплыйлар. Сталинградны азат итү операциясе «Уран» дип атала бит, шуннан күрмеш, Ржев өчен сугышны да «Марс» дигән яңгыравык исем белән билгелиләр. Һөҗүм 25 ноябрьдә атлы дивизия ташкыны белән башлана. Фашистлар тоташ пулемет уты белән каршылый, беренче көнге яуда ук 8295 совет сугышчысын юк итәләр. Югалтуларны Себердә тупланган резерв хисабына янә тутыралар. Декабрь уртасына кадәр кабатланып торган һөҗүмнәр һичбер төрле нәтиҗә дә бирми. Гаҗәеп хәл монда да тиз табыла. Шушы Ржев янында коточкыч теткәләнгән 39 нчы армия калдыкларын яңа алмаш белән тулыландыралар. Генерал Зыгин аның яңа башлыгы булып билгеләнә. Һәм менә шушы армия каршына килеп, Жуков шәхсән үзе генерал Зыгинны капкачына «Оленино каласын алган өчен» дип язылган кыйммәтле сәгать белән бүләкли. Әкәмәт вә сәер: Оленинoны фәкать өч айдан, Ржевтан соң гына азат итәләр әле...

Ә совет гаскәрләренә Ржев каласы өчен инде бүтәнчә кан коеп торырга да туры килми. Хәнҗәр шикелле тырпаеп торган Ржевны совет гаскәрләренең барыбер штурмлаячак икәнен аңлап, генерал Модель аны сугышсыз-нисез калдырып китү өчен Гитлерның шәхсән үзеннән рөхсәт алуга ирешә. Өстәвенә, 1943 елның 19 февралендә Сталинград янындагы яу да тәмамлана, совет Ставкасының анда бушаган көчләрне Ржев юнәлешенә күчереп куюы мөмкин бит. Совет разведкасының игътибарын җәлеп итмичә генә чигенүне «Буйвол операциясе» дип атыйлар. Генерал Модель Ржев плацдармын 18 ай буе үз кулында тоткан 9 нчы армия полкларын берәм-берәм һәм фәкать төнлә генә шәһәрдән чыгара башлый. Окоп-блиндажларда көндез «кузгалмыйча ятучы» батальоннар «төтен җибәрә», ә төннәрен чираттагы полк үз позициясен калдырып чигенә. 1 мартка фашистлар тулысынча Ржев каласын калдыра, Идел аша совет власте салган тимерьюл күперен генә арьергард көч саклый. 2 март төнендә әлеге күпер нигезләренә шартлаткыч тезәләр. Генерал Модель Берлиндагы Гитлер белән элемтәгә керә:

– Хәзер без Идел аша салынган күперне күккә очырабыз, шушы тантанага сез дә шаһит булсагыз иде, бөек фюрер.

Дәһшәтле мина һәм фугаслар ут бөрки, елга күперенең калдыклары төрле якка оча. Арьергард отрядлар да төнге караңгылык эченә чумып юкка чыга...

3 март иртәсендә совет гаскәрләре Ржев өстенә ябырыла, тәүге рәтләр немец траншеяларына килеп җитә һәм, тамаша күргән төсле, «Монда фриц юк бит!» – дип сөрән салырга мәҗбүр була...

Сталинга генерал Модельнең ни рәвешле биткә төкереп койрык ялтыратуы турында ярты елдан соң гына сөйләп бирергә җөрьәт итәләр. Хакыйкатьне ишетеп шаккаткан Сталин 9 сентябрь кичендә юлга җыенырга әмер бирә. Баш җәллад Берия, генерал Еременко, башка куштаннар озатуында килеп, ул Модель шартлатып киткән тимерьюл күпере янында басып тора. Хурлык кичерердәй вөҗданы булмагандыр, дәшми-тынмый гына кабат юлга чыга. Куштаннар янәшәдә генә бит, ниндидер рәссам табылып, ул «Сталин үзе азат иткән Ржев каласы янында, Идел ярында» дип тамгаланган «шедевр» иҗат итә. Картина бүген дә исән-сау...

«Хәрби энциклопедия» Ржевны азат итү өчен дүрт мәртәбә үткәрелгән операция барышында 433 мең сугышчы һәлак булган, дип бара. Хәрби тарихчылар Ржев һәм Вязьма янында кырылган сугышчылар һәм фашистлар юкка чыгарган тыныч халыкны да искә тотып, корбаннар санын миллион ярымга җиткерә. Немецларның 9 нчы армиясе 18 ай буена барган оборона сугышларында 120 мең чамасы солдат югалта. Хисап дүрткә – бер, хәтта уникегә – бер чамасы туры килә. Юанырлык түгел. Ветераннар әле булса мондагы яуларны, кыска гына, «Ржев иттурагычы» дип сызланып искә ала...

Сталинның «Кутузовлыгы» ничә йөз мең яки миллион корбан белән түләнгәндер, моны санаучы юк. Янә бер яман як: без санаган Волхов, Ржев, Вязьма «казаннары» аркасында Кызыл Армия унөч ай буена, Сталинград җиңүенә чаклы уңыш кичерә алмыйча, бер урында таптанырга мәҗбүр була...

Ә Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, беренче җәйдә үк Вязьма каласы халкын 33 нче армияда, генерал Ефремов кул астында хезмәт иткән солдатлар шаккатыра. Алар аз да түгел, күп тә түгел, 800 гә якын булып җыела. Арада бик тә укымышлы һәм законнарны төптән белүче офицер табылгандыр, шуның өйрәтүе буенча язылган мөрәҗәгатьне шәһәр хакиме өстәленә кертеп салалар. «Шәһәрнең үзәк мәйданына генерал Ефремов исемен беркетегез, анда төп-төгәл бер елдан соң аның үзенә һәм сугышчыларына багышланган һәйкәл дә басып торырга тиеш. Менә без үзебезгә фронттагы айлар буенча бирелгән жалованиене җыйдык. Һәйкәлнең нигезе шул булыр. Сүзебезне аяк астына салсагыз, байтагыбызның коралы икәнен дә онытмагыз».

Бил каешларына пистолетлар тагып кергән офицерларны күргәч, кайсы гына хаким үтенеп килүчеләрнең сүзләренә колак салмас икән? Бу хакта хәбәр әүвәл өлкә башлыкларына, аннары Сталинның үзенә үк барып ишетелә. Аның фәрманы буенча конкурс игълан итәләр. Һәйкәл проектлары бәйгесендә Муса Җәлил белән бер үк «Отвага» газетасында эшләгән рәссам Евгений Вучетич рәсеме җиңеп чыга. Вучетич һәйкәлне якындагы бер җимерек чиркәүне арендалап ясый. 1946 елның 7 ноябрендә Вязьма каласы уртасында менә инде сигезенче дистә ел буе меңнәрләгән сәяхәтчене, барыннан да бигрәк шәһәрдәшләрнең күзен сөендереп, мәһабәт һәйкәл басып тора. Хөкүмәт бик соңарып, фәкать 1996 елда гына генерал Ефремовка «Россия Каһарманы» дигән исем дә биреп куя...

Диван яки креслоларга кырын яткан көе генә совет солдатларының Тверь каласын саклап калуы яисә Ржев каласы янындагы бәрелешләрне сурәтләгән уйдырма киноларны карарга күптән күнектек без. Тик анда сурәтләнгән вакыйгалар чынбарлыкка һич тә туры килми...

Вахит ИМАМОВ.

Чыганаклар:

Алексей Пивоваров. Ржев: неизвестная битва Г.Жукова. «НТВ» каналы, 2010 ел, 27 октябрь.

В.Млечин. Генерал Ефремов. Смерть героя. ТВЦ, 2015 ел, 16 декабрь.

Вяземский котел. ТНВ, 2015 ел, 9 июнь.

В.Абатуров, М.Морозов. Неизвестные трагедии Великой Отечественной. Сражения без побед. Электрон китап.

Википедия. Вяземско-Ржевская наступательная операция.

Уралдагы

Себер ханлыгының борынгы башкаласы Искәрне күпләр белә, ә менә Төньяк Уралда да шул исемдәге урын барын белүчеләр аздыр. Пермь краеның иң төньяк чигендә, Чердын белән Ныроб арасына урнашкан ул. Искор җирле коми телендә «таш кала» дигән мәгънәне аңлата икән. Безнең өчен Искәр – иске җир, борынгы җир, дигән сүз.

Уралдагы Искәргә нигез 1472 елда салынган, диләр, бу – Мәскәү гаскәренең Пермь төбәген басып алган чагы. Искәрдән 5 чакрымнар ераклыкта, урман эчендәге тау башында, борынгы шәһәрлек урыны да бар. Авыл да, шәһәрлек урыны да инде ташландык хәлдә, җимерек чиркәү һәм часовнялары гына тырпаеп тора...

Менә без ташландык Искор шәһәрлеген карарга барабыз. Без, дигәнем – Пермь крае мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Рәхмәтуллин, мин фәкыйрегез, Березники шәһәреннән Илдар Бәдретдинов һәм Чердыннан безгә ярдәмгә бирелгән гид-экскурсовод. Юлыбыз мул сулы Колва елгасы буенча бара, елга ярларында анда-санда чиркәүле урыс-коми авыллары күренеп кала. Әмма чиркәүләре ярымҗимерек. Хәер, юл буендагы бу авыллар үзләре дә шактый фәкыйрь күренә, аларда халык бары тик урман һәм елга белән туенып яши икән. Авылларга түгел, Чердынның үзенә дә табигый газ кертелмәгән, эш юк, иген кырларын яңадан урман баскан... Бу тайга урманнары бирердән котыпка хәтле сузылган, төньякка таба торак урыннар юк диярлек.

Безнең гидыбыз урыс телле коми ир-аты булып чыкты, әмма үз телен белми, урыс динен тотмый, үзен атеист, ди. Әмма Искорда урыс часовнясы бар, ул өч мөселманга шуны күрсәтмәкче. Анда татарлар турында да хәбәр бар, ди, шуңа иярдек тә. Ул тау бик текә булып чыкты, аста упкын булып тайга җәйрәп ята... «Мондый җайсыз җирдә шәһәрлек булмаган, казып карадылар, бер нәрсә табылмады», ди гидыбыз. «Алайса, нигә ул тау башына часовня менгереп салганнар соң?», дибез. «Монда сугыш булган, Параскева Пятница исемле хатын җәзалап үтерелгән, диләр, часовня да шуның хөрмәтенә салынган». «Монда кем белән кем сугышкан соң?» «Татарлар белән руслар сугышкан, Параскева Пятницаны да шулар үтергән, дип язалар...»

Кат-кат сорашмасам да, мондый гыйбарәнең әкият икәнлеген яхшы беләм. Хәер, тау астындагы стендта да бу урынның кыскача тарихы язылган. Имеш, башта бу урын – Искор шәһәрлеге – мәҗүси коми халкының табыну урыны, хәтта башкаласы булган, имеш, анда Кор исемле патша яшәгән, шул дошманнар монда Параскева Пятницаны кулга төшергән, аны җәзалаган. Ул, имеш, христиан динендә булган, крепость эчендәгеләр, аның ничек газапланыуын күреп, бирелергә тиеш булган, ә ул хатын, бирелмәгез, дигән, тегеләре, имеш, дошманга бирелмәгән һәм җиңгән... Кыскасы, сүз боткасы. Мәгәр, менә, тау башында Параскеваның иконасы пәйда булган бу урынга часовня салганнар һәм аңа изге Параскева Пятница исемен биргәннәр. Ул башта агачтан булган, 1891 елда аның урынына таштан часовня салып куйганнар. Һәм Искәр авылы халкы хәзер ел саен шушы урынга тәре йөрешләре оештыра икән...

Шул часовня каршында басып торабыз. Зур булмаган, шакмаклы кирпеч бина, тышы акшарланган, эче шул килеш калган. Ни кызганыч, 1893 елда часовня стенасына ясалган рәсемнәр инде юкка чыккан, ишек өстендәге язуда да «защита жителей Искора от ногайских татар...» дигән сүзләрне генә шәйләргә була. Югыйсә, монда «тарихи» рәсемнәр ясалган булган бит! Чердын музее тарафыннан чыгарылган «Часовня Параскевы Пятницы» открыткасының артына болай язылган: «На северной стороне изображена сцена крещения жителей Перми Великой в XV веке. Над входом запечатлен момент защиты городка Искор от набега татар»...

Кем белән кем сугышканын белдек – татарлар белән руслар Төньяк Уралны бүлешкәннәр икән, ул чакта әле Пермь үзе дә, сүзе дә булмаган. Инде хәзер ачыклык кертик – бу хәлләр кайчан булган соң? Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, 1472 елда Федор Палецкий Пестрый җитәкчелегендәге Мәскәү яугирләре бу төбәкне канга батырып буйсындыра, Искор шәһәрлеген җимерәләр, ут төртеп яндыралар, җирле халыкны кылычтан үткәрәләр. Бу хәтле явызлыкның төп сәбәбе, имеш, алар Казан ханлыгына каршы сугышта Мәскәү князьлегенә ярдәм итмәгән икән. Озак еллар буе үзе дә Болгар, Алтын Урда, Казан һәм Себер ханлыклары составында булган татар-коми Чердыны ничек инде, урыслар куша, дип, Казан ханлыгына каршы яу чапсын, ди?! Һәм ризалашмаган өчен ул үзенең бәйсезлеге белән түли...

Чердын музее директорыннан «Параскева Пятница кайсы милләттән булган?», дип сорамыйча түзмәдем. Рус милләтеннән, дияр иде, Искор шәһәрлеген руслар үзләре 1472 елда ут төртеп яндыра, җимерә бит! Ул вакытта әле бу тирәдә руслар яшәмәгән, ара-тирә баскыннар һәм аларга ияреп килгән поплар гына күренгәләгән. Димәк, Параскева анакайлары берничек тә рус милләтеннән була алмый! Коми-пермяк, дияр идең, алар ул вакытта мәҗүсиләр була, юлбашчылары ислам динен тота, ә бу хатын христиан диненең изгесе санала! Директор ханым бу сорауга җавап бирә алмады, ул христиан булган, дип кенә чикләнде. Христиан булгач, нигә аның йортын – Искорны христиан урыслар юк итә соң? Монда бер нәрсәнең дә очы-очка ялганмый, аның каравы бөтен тарихи язмалар татарларны гаепләү белән тулган, имеш, алар монда басып кергән, җирле халыкны аскан да суйган икән...

«По местным легендам, городок страдал от набегов татар, – дип яза алар. – Как гласит предание, сражение русских ратников с ногайскими татарами происходили при местном царе Коре на подступах к древнему Искору. Возле современного села Искор среди полей до сих пор сохранились «острова убиенных» – две рощи елово-пихтового леса. Одну из них называют «русским островком», а вторую – «татарским островком и чудским», по похороненным там погибшем». (Павел Распопов. https://uraloved.ru/iskorskoe-gorodishe-i-uzkaya-ulochka.)

Безнең өчен монда иң мөһиме – Искор авылы янындагы татар каберлеге. Бу төбәкнең мең еллар элек үк Идел Болгарстаны дәүләте составында булуы, Чердынның болгар-татар мөселманнарының башкаласы булып торуы турында язган идек инде. Чердын өчен татарлар белән руслар арасында унбер сугыш булуы да тарихта теркәлеп калган. Башкала өчен шундый каты сугышлар булган икән, аның тирә-ягындагы авыллар өчен дә канлы яулар барган. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, без өйрәнә торган Искор-Искәр дә князьлекнең үзенә булып тора, шуңа күрә ул зур хәрби әһәмияткә ия була.

Урыслар тарихи чыганакларда һәм елъязмаларда «Пермь Великая» дип аталган Чердын җирләре өчен көрәш Алтын Урда дәүләтенең таркалу елларына туры килә. Аңа хәтле урыслар бу тирәләргә борын тыгарга шүрли, тагын да төньяктарак булган Усть-Вымьнан ары уза алмый. Бу хакта урыс тарихчылары үзләре дә ачыктан-ачык яза, бары тик татарлар хуҗа булганга гына бөтен Төньяк Уралны басып ала алмауларын таный:

МӘК – тамаша залларына чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

22 декабрь – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).
23 декабрь – Шәрык клубында 14.00 – Балалар өчен рәсем остаханәсе. 15.00 – «Кышкы тылсым» квесты. Зур залда 18.00 – «Әтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев).
24 декабрь – Шәрык клубында 14.00 – «Кышкы тылсым» квесты. Зур залда 18.00 – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
25 декабрь – Шәрык клубында 14.00 – «Кышкы тылсым» квесты.
26 декабрь – Шәрык клубында 14.00 – «Кышкы тылсым» квесты. Зур залда – 19.00 – «Игезәк» (Р.Зәйдулла).
27 декабрь – Шәрык клубында 14.00 – «Кышкы тылсым» квесты. Зур залда 19.00 – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
28 декабрь – Шәрык клубында 14.00 – «Кышкы тылсым» квесты. Зур залда 19.00 – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

22, 23 декабрь – «Летучая мышь» (И.Штраус).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

22 декабрь – «Яратам! Бетте-китте!»
23 декабрь – 12.30 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 17.00 – «Кияү урлау» (С.Юзеев, Х.Ибраһим).
24 декабрь – 12.30 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 17.00 – «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов).
26 декабрь – 13.00 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 18.30 – «Назлы кияү» (К.Тинчурин).
27 декабрь – 13.00 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 18.30 – «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин).
28 декабрь – 11.00 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 18.30 – «Акча бездә бер букча» (З.Хәким).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

22-29 декабрь – «Көлсылу һәм Яңа ел бәйрәме» тамашасы.

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

22-29 декабрь – «Морозко» Яңа ел тамашасы.
23 декабрьдә 14.00, 16.00, 18.00 да спектакль татар телендә башкарыла.

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

23 декабрь – Татарстан дәүләт филармониясе джаз оркестрының «Новогоднее шоу маленького волшебника» дип исемләнгән тамашасы.
24 декабрь – 10.00, 13.00 – Татарстан дәүләт филармониясе джаз оркестрының «Новогоднее шоу маленького волшебника» дип исемләнгән тамашасы. 16.00, 18.30 – «Нехочуха» спектакле.
25 декабрь – «Новогодние приключения Буратино» спектакле.
26, 27 декабрь – Филармония джаз оркестрының «Новогоднее шоу маленького волшебника» спектакле.
28 декабрь – 13.00 – «Нехочуха» спектакле. 18.30 – «Маленькие истории о большой любви» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә.

Искор-Искәрдә...



«Пермская земля издревле привлекала к себе внимание русских князей, и только монголо-татарское иго тормозило ее колонизацию, – дип яза алар. – После распада Золотой Орды происходит бурный рост Московского княжества за счет присоединения уделов Северо-Восточной Руси и земель северного Приуралья». (Защитники Перми Великой. – Чердынь, 2007, стр.4.)

Урысларның Төньяк Уралга 1472 елгы яулары аерата рәхимсез була, 4 мең кешелек җәза отряды белән Великий Устюгтан бирегә килеп, алар 41 шәһәр һәм авылны утка тота, канга батырып басып ала, җирле халыкларның 58 юлбашчысын кылыч астында Россиягә баш ияргә мәҗбүр итә, коллык белән ризалашмаган бик күп татарларны юк итәләр. (Бу хакта мәгълүмат: Алексеев М.П. Сибирь в известиях западно-европейских путешественников и писателей. – Иркутск, 1941, стр.134; Устюжеский летописный свод. Стр.167, 168, 189, 209; Габдельбар Файзрахманов. История Сибирских татар. – Казань, 2002, стр.181.)

Искор-Искәрне дә менә шундый язмыш көтә, 1472 елда ул да ут һәм кылыч белән Мәскәүгә буйсындырыла, әмма аның өчен көрәш тукталмый, ул XVI гасырда да дәвам итә. Казан һәм Себер ханлыклары Төньяк Уралны яңадан татарларга кире кайтару өчен көрәшә. 1535 елда себер татарлары урысларның ул чактагы башкаласы Покчаны ут төртеп яндыра, шуннан соң үзәк Чердынга күчерелә, сугыш җилләре Искорга да кагылмыйча калмый. 1545 елда башта Түбән Новгород, Вятка, Чердын урыслары Казан өстенә яу белән бара, анда аларның үзләрен юк итәләр, ә инде 1546 елда, җавап итеп, Казан ханы Сафагәрәйнең ногай-татар гаскәре Пермь җирләрен килеп туздыра, ике яктан да меңәрләгән кеше һәлак була. Искор тирәсендәге татар каберлеге бәлки шул вакытлардан калгандыр, бәлки себер татарларының шул гасыр азагындагы яулары белән бәйледер...

Казан җиңелгәч, Пермь җирләре, анда кол хәлендә яшәүче татарлар өчен көрәшне Себер ханлыгы дәвам итә, аларга җирле вогул, коми халыклары да кушыла. Ул чакта җирле халыкларның күпчелеге, бигрәк тә аларның юлбашчы-князьләре инде ислам динендә була һәм бу сугышлар дини төсмер дә ала. Строгановларның тимер һәм тоз базларында чылбырларга бәйләп куеп эшләткән татар һәм коми-вогулларны азат итү өчен, 1573 елда Себердән 10 меңлек кешелек татар гаскәре килә һәм сугышып, кол халыкны азат итә. Яу белән Күчем ханның улы Али солтан һәм абыйсының улы Мөхәммәткол идарә итә, алар бу тирәдәге күп кенә сала һәм калаларны азат итә, төрмәләрне җимерә, Строгановлар үзләре Соликамскига качып котыла.

1582 елда мондый яу тагын кабатлана, бу юлы – ике яктан да. Ягъни, Строгановлар Себер өстенә Ермак бандасын кораллландырып җибәрә, ә аларга каршы Себердән Уралга татар явы кузгала, аның белән Күчем ханның олы улы Али солтан идарә итә. Чердынның урыс воеводасы Пелепелицын Мәскәү патшасы Иван Грозныйга зарланып хат язарга мәҗбүр була, «Строгановы послали своих казаков 1 сентября в Сибирь, и в тот же день на Пермь Великую (Чердын) напали кучумляне и пелымские манси, осадили город и многих людей побили...» (Чердынь и Урал в историческом и культурном наследии России. – Пермь, 1999, стр.275.) Тарихта сирәк була торган гаҗәеп хәл – шушы ук вакытта Ермак Себер ханлыгының башкаласы Искәрне яулап ала, аны, халыкны харап итмәс өчен, Күчем хан үзе вакытлыча калдырып чыга, Уралда исә татар гаскәре Чердынны һәм Искорны яулап ала. Ике Искәр, уртак язмыш... Ермак Себердә үзенең үлемен таба, Али хан җиңүче булып иленә кайта һәм Искәрне яңадан торгыза...

Себердә дә, Уралда да бу тарихи вакыйгаларны онытмыйлар, татар Искәрендә – дога белән, Урал Искорында театраль тамашалар белән билгеләп үтәләр. Себердәге Хәтер көнендә үзем дә ел саен катнашам, ә Уралдагы Искор җыены турында укып кына беләм. Шундый тамашаларның берсе 2001 елның 14 сентябрендә Искор авылыннан ерак түгел Бастарып кырында уздырыла һәм «Набег ногайских татар из Сибири на городок Искор в 1581 году» дип атала. Әлбәттә, датасы да, вакыйгаларны тасвирлау да дөрес түгел, ногайлар канәчкеч вәхши итеп тасвирланган, имеш, урманнан чыгып, тыныч кына яшәп яткан урыс гаиләсен үтерәләр, урыслар һәм татарлар арасында зур сугыш башлана, ике яктан да күп кеше үлә, һәм әлбәттә, урыслар җиңә. Бу сценарийны Чердын хакимияте әзерләгән, тамашаны ачык кырда меңгә якын кеше караган, алар арасында бөтен Россиядән җыелган галимнәр, сәнгатьләр дә булган...

Ирексездән, тагын чагыштырасы килә. Себер ханлыгы башкаласы Искәрне татарлар яңадан торгызды, анда Күчем хан мәчете, музей, кунакханәләр үсеп чыкты, ел саен Хәтер көннәре, фәнни җыеннар уздырыла, туристлар өзелми. Ә Уралдагы Искор-Искәр җан биреп ята, авылда нибары йөзләп кеше яши, юллар да, табигый газ да, эш тә, киләчәк тә юк. Күрсәтергә XVIII гасыр азагында салынган, хәзер инде җимерек хәлгә килгән таш чиркәү һәм җимерек бай йорты гына утырып калган. Чиркәүнең элеккеге күренеше Сөембикә манарасын хәтерләтә, ул кызыл кирпечтән һәм биш ярусы булган. 2004 елда чиркәүнең тәресен яшен суккан һәм яшен уты аскы катка хәтле яндырып, җимереп төшкән... Хәзер ул ташландык хәлдә. Хәер, Төньяк Уралда күпчелек урыс авыллары ташландык хәлдә, күп авыллар беткән, кырларга яңадан урман үскән, элек монда кешеләр яшәгәнен исбатлап, урман уртасында җимерек чиркәүләре, часовнялары гына утырып калган.

Хәер, Пермь краеның төньягында инде татар авыллары да калмаган, ә алар булган бит, булган! Узган гасырларда Чердын өязендә төрки-татар атамалы Гайнә, Тулпан, Искәр, Курья, Кокуй, Солтан, Баяндин, Керчь, Турчанка, Черепан-Чурапан, Тал, Бондюг, Муртым, Юмыш, Күтәмеш, Ширәмәт, Вәриз, Сакин, Бигич, Урол, Булат, Урос, Курган, Будым, Чуртан, Кебрат, Солым, Татар авыллары да булган бит! Бу тирәдәге елга-су атамалары да татарлыкка шәһадәт биреп тора – Кама-Чулман, Тимшәр, Шөгер, Килтмә, Улыс, Чу суы, Бигич күле, Кимзил, Мудыл, Сәрдә… Әйе, милләт киткән, башка халәткә күчкән, ә җир-су атамаларында гомерлеккә исеме уелып калган… Менә хәзер шуларны барлап йөрибез, чөнки бу кара урманнарда, кыя-таулар арасында әле ачылмаган татар тарихы җәйрәп ята…

Фәүзия БӘЙРӘМОВА.

Айга карама кырын

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

23 декабрь (шимбә). ***Җөмәдел ахир аеның 10 нчы көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 13.24 сәгатьтә калка, 5.00 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.00 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Куркум сихәте (1)

Куркум (һинд зәгъфраны) – иң күп кулланыла торган тәмләткечләрдән берсе, аның файдалы үзлекләре бихисап. Куркум йод, фосфор, тимер, кальций, витаминнар, эфир майлары, антиоксидантларга бай, аны даими куллану яман шеш килеп чыгу ихтималын, кандагы шикәр микъдарын, ашказанынының кислоталылыгын киметә, иммунитетны ныгыта, кан әйләнешен яхшырта. Куркум кулланганда, ризык майга түгел, энергиягә әйләнә. Салкын тигәндә, шулай ук канны чистарту өчен, ярты стакан кайнар суга ярты чәй кашыгы куркум һәм 1 чәй кашыгы бал салып, өстен каплап, 5 минут төнәтәләр, тәүлегенә 2-3 тапкыр яртышар стакан эчәләр. Йөткергәндә, температура югары булганда, салкын тигәндә, чирегешәр чәй кашыгы куркум белән балны кушып, көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, кабалар. Ютәлләгәндә, 1 стакан сөтне кайнатып, аннары 60 градуска кадәр суыталар, 1 әр чәй кашыгы бал һәм куркум кушып, йоклар алдыннан эчәләр.

24 декабрь (якшәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 11 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 13.40 сәгатьтә калка, 6.34 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.00 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Куркум сихәте (2)

Ангина, фарингит булганда, бүлмә температурасындагы суда берәр чеметем куркум һәм тозны эретеп, тәүлегенә 4 тапкыр авызны чайкыйлар. Диабет интектергәндә, ашар алдыннан өчтән бер чәй кашыгы куркум кабып, су эчәләр. Эч күпкәндә, ашказаны авыртканда, ярты чәй кашыгы порошокны 1 стакан суда эретеп, ашар алдыннан эчәләр. Буыннар авыртканда, бал, куркум һәм имбирне тигез микъдарда кушып, көненә берничә тапкыр, ашар алдыннан кабалар. Урт канаганда, 1 чәй кашыгы порошокны 1 стакан кайнар суга салып, авызны чайкыйлар. Агулангада, ризыкка куркум сибеп ашыйлар. Азканлылык булганда, яртышар чәй кашыгы бал һәм куркумны кушып, көненә 3 тапкыр кабалар.

25 декабрь (дүшәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 12 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 14.06 сәгатьтә калка, 8.03 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.00 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

26 декабрь (сишәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 13 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 14.45 сәгатьтә калка, 9.21 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.00 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

27 декабрь (чәршәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,16.55 сәгатьтә калка, 10.56 сәгатьтә бата. 3 сәгать 33 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 7.00 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

28 декабрь (пәнҗешәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 15 нче көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 16.55 сәгатьтә калка, 10.56 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.01 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Борычлы май

Радикулит, ревматизм интектергәндә, буыннар сызлаганда, борычлы май белән дәвалану файдалы. 100 грамм үсемлек маена 1 аш кашыгы төелгән кара борыч кушып, сүрән утта кайнатып чыгаралар, 5-6 минут кайнаткач, сүндереп, суыталар. Суыткычта саклыйлар. Кулланыр алдыннан кирәк кадәрен генә бераз җылытып, авырткан урынга сеңеп беткәнче ышкыйлар, җылы тукыма белән урап, бер-ике сәгать тоталар. Каты яндыра башласа, тирене үсемлек маенда чылатылган тампон белән чистарталар.

29 декабрь (җомга). ***Җөмәдел ахир аеның 16 нчы көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 18.14 сәгатьтә калка, 11.18 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.02 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Шоколадлы-чикләвекле печенье

Нью-Йоркның атаклы Levain Bakery икмәк пешерү йортында әзерләнә торган печенье бу. 115 г салкын атланмайны миксер белән күпертеп, 190 г шикәр, 1 йомырка өстәп тагын туглыйлар, 245 г он, 1 аш кашыгы кукуруз крахмалы, 1 чәй кашыгы камыр күпшәкләндергеч, 0,5 чәй кашыгы тоз кушып, камыр басалар. Вакланган 60 г әстерхан чикләвеге белән 200 г шоколад өстиләр дә, 100 әр граммлы шарчыклар әвәләп, пергамент кәгазе җәелгән табага тезәләр, суыткычта 1 сәгать суыталар. Аннары 170 градуслы газ мичендә 17-20 минут пешерәләр.

Алсу, Алсу, йөрәк ярсу...

«Мәдәни җомга» газетасының тәрҗемәче-редакторы Алсу Наил кызы Зәйдуллинага бу көннәрдә 55 яшь тулды. Тырыш, һәрвакыт белемгә омтылучы, бар эшне дә җентекләп, төгәллек белән башкаручы, кызыксынучан, милли җанлы Алсу өчен ике бишле килешеп тора. Узган гомергә әйләнеп карап, һәрьяклап бәяләгәч, аның бишлеләргә чыннан да лаеклы икәнлегенә инанасың.

Кышкы салкыннарда, дулый-дулый буран уйнаган декабрь аенда дөньяга аваз салган Алсуыбыз табигатьтән нечкә күңелле, сабыр, тыйнак һәм ярдәмчел. Кешенең нинди генә булуына карамастан, ул ничек бар шулай кабул итә, иркенләп аралаша, һәркем белән яхшы мөнәсәбәт урнаштыра, кирәк чакта киңәшләрен дә бирә.

«Азатлык» татар яшьләре берлегендә ирек даулап йөргән яшь чаклар... 1990 ел .

2022 елны озатканда.

Редакция белән өмәдә. 2009 ел .

Нурлат районының борынгы татар авылы – Кычытканлыда туып-үскән Алсуны укытучы булу хыялы Казан дәүләт педагогика институтына алып килә. Студент еллары татар халкының милли күтәрелеш чорына туры килә. Мәктәптә ана телендә төпле белем алган, гаиләдә милли гореф-гадәтләргә таянып тәрбияләнгән Алсу җәмгыятьтә барган үзгәрешләрдән читтә кала алмый. Үзе кебек Казанның уку йортларында белем алучы татар яшьләре белән танышып, иҗтимагый тормышта кайный башлый. Бергәләшеп, тарихта беренче тапкыр «Идел» яшьләр лагеренда бүгенге көндә дә дәвам иткән Бөтендөнья татар яшьләре көннәренә нигез салалар. Вазгыятьнең иң кискен, Татарстанның киләчәге хәл ителгән вакытта тәүлек буе чиратлашып Ирек мәйданында сәяси ачлык тотучыларны саклыйлар. Дәүләт имтиханын тапшырырга да ул нәкъ менә мәйданнан юл ала. Диплом алгач, Казанның яңа ачылган 13 нче татар гимназиясендә укыта.

Алсу балачактан әдәбиятка гашыйк. Ике телдә дә рәхәтләнеп әдәби әсәрләр укый. Халкыбызның әдәби мәтрләры – Г.Исхакый, Ә.Еники, М.Мәһдиев әсәрләренә мөкиббән. Күп укырга яраткангамы, аңа зирәк акыллылык хас. Белемгә омтылу, һәр нәрсәне аңлап белү – күңел таләбе. Болар барысы да Алсуга табигатьтән бирелгән чиксез байлык. Һәм ул моны күңеле белән тоемлап, тормышында да, эшчәнлегендә дә кулланырга тырыша.

«Мәдәни җомга» газетасында тәрҗемәче-редактор буларак эшли башлавына да инде 20 ел тулды. Газетада Алсу укучылар яратып, кызыксынып укый торган «Айга кырын карама» һәм «Җиһан шаһит» рубрикаларын, «Чуардан-чуар дөнья» сәхифәсен алып бара. Кирәкле материалны эзләп табып, җентекләп өйрәнеп, иң кызыклысын һәм иң файдалысын сайлап, укучыларның һәркайсына аңлашылырлык итеп җиткерә белә. Ходайдан бирелгән тел байлыгы, төрле яклап күрә белгән күңел күзе, еллар буенча тупланган тәҗрибә – аның профессиональ эшчәнлегендәге алыштыргысыз юлдашчылары. Эшен бик яратып, зур җаваплылык белән башкара.

Хәләл җефете Рәис белән үз нигезләрен булдырып, гаилә учагы кабызып, ике бала тәрбияләп үстерәләр. Бүген Алсу – сөекле хатын һәм бәхетле әни, колач җәеп каршы алучы дәү әни, уңган һәм кунакчыл хуҗабикә. Алсуның олы ихтирамга лаек тагын бер ягы бар – ул бик туган җанлы хатын-кыз. Туганнарының хәл-әхвәлләрен белешеп, мөмкинлек чыкканда җыеп, күрешеп, аралашып яши. Кунаклар җыелганда һәркайсын кайгыртып, йөрәк җылысы белән җылытып, үзенә генә хас назы белән иркәләп, күңелләрен күреп, тәмле ризыклары белән сыйлап кунак итә.

Кадерле вә гыйззәтле хезмәттәшебез Алсуны туган көне белән тәбрик итеп, иң изге теләкләрне юллыйбыз. Гаилә учагы сүнмичә, сүрелмичә, яктырак янсын. Язмыш җилләре бары тик куанычлар гына китерсен. Һәр көне якты хатирә булып тормыш китабына язылып барсын. Балаларының һәм оныкларының рәхәтен күреп, бәхеткә-шатлыкка төренеп яшәргә насыйп булсын.

«Мәдәни җомга» газетасы коллективы.

АТ КАРАГЫ

Әлмәт театрында сәхнәгә Туфан Миңнуллинның «Ат карагы» драмасы куелды. Танылган драматург, фәлсәфәче әдип Туфан ага иҗаты һәрвакыт зур кызыксыну уята. Шуның өстенә узган октябрь аенда сәхнәгә менгән спектакль матбугатта шау-шу уятырга да өлгерде.

«Ат карагы» пьесасы Т.Миңнуллинның киң җәмәгатьчелек яратып кабул иткән, сәхнәләрдә кат-кат уйналган әсәрләре арасында түгел. Һәрхәлдә аның иҗат йөзен беренче чиратта «Әлдермештән Әлмәндәр», «Әниләр һәм бәбиләр», «Дуслар җыелган җирдә», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Моңлы бер җыр», «Шәҗәрә», «Саташу», «Мулла» кебек пьесалары билгели. Әмма Туфан ағаның бербөтен иҗатында «Ат карагы»да мөһим урын тота. Драматург иҗатта «татарның кем һәм нинди булуы, кайсы сыйфатларның характерын билгеләве, бүгенгесенә таянган хәлдә киләчәге нинди булу» кебек сорауларга җавап эзли. Стиль үзенчәлеге буларак, җавап вариантларын тәкъдим итеп кенә калмый, бәлки укучы-тамашачының да алар турында уйлануына этәрә. Татар халкының социаль бүленешендә төрле катлам кешеләр булган: рухание, бае һәм ярлысы, крестьяны һәм эшчесе, зыялысы, теләнчесе һәм ат карагы... Тарихтан билгеле: татар кешесе җиргә береккән, җир эшкәртү – аның канында. Әмма гасырларга сузылган кимсетелеп яшәү, җирсезлек аны башка җирләргә күчеп китәргә мәҗбүр иткән кебек, төрле социаль катлауларга да бүлгән. Кемдер бурлак булып Иделдә баржа тарткан, икенчеләр шахтада күмер чапкан, читтә йөрүне көсеп иткән зимагурлар төркеме дә пәйда булган. Билгеле, ат караклары күп булмагандыр, чөнки алар җинаятьче саналып, һәрвакыт эзәрлекләнгән. Бу шөгыльгә алынучыларның гаярь, үткер, башбирмәс кешеләр булуы да аңлашыла.Шуңа да ат урлап көн күрүчеләр турында төрле риваятьләр таралыш алган. Кайбыч районы Чүти авылында яшәгән атаклы Шәкүр карак исеме XX йөз башында киң таралган була. Совет власте урнашканнан соң да бу шөгыленнән баш тартмаган бу кешене 1926 елда атып үтерүләре мәгълүм. Аның гыйбрәтле язмышы Туфан аганы да битараф калдырмаган. Ул Шәкүр карак яшәгән авылда булып, аның белән бәйле истәлекләр, суд эше документларын өйрәнгән. Нәтиҗәдә 1972 елда «Ат карагы» драмасы языла. Әсәрне Г.Камал театры сәхнәләштерә, әмма ул озын гомерле булмый. Пьеса язылып ярты гасыр вакыт үткәч, режиссер Айдар Җаббаров аны Әлмәт театры сәхнәсенә менгерә. Автор ат карагы Сибгатне патша властен, һәртөр изүне кабул итмәгән, ярлы халыкка ярдәм итеп яшәгән, әмма кыйбласын таба алмаган кеше итеп сурәтли. Пьеса нигезендә Совет власте крестьянга җир биреп, аның киләчәк юлын күрсәтә, әмма герой үзен-үзе җиңә алмый, бертөрле властька да буйсынасы килми һәм шуның белән үз гомерен чикли, дигән фикер ята.

Әсәрне сәхнәгә куюга алынган А.Җаббаров алдында авыр сораулар тора: автор пьесага салган идеяне заман тамашачысы кабул итәргә әзерме? 100 ел элек булган хәл-күренешләрне нинди алым-чаралар, мизансценалар аша ачып була? Режиссер һәм аның командасы пьесадагы аерым күренешләргә үзгәреш кертә, урыннарын

алыштыра, деталь-билгеләр белән баета. Алар, нигездә, аклана. Спектакльне эшләү барышында А.Җаббаров рәссам буларак та эш итә, аның ярдәмчеләре – Энже Сәйфетдинова, хореограф Полина Майорова, хормейстер Марат Яхъяев.

Спектакль ат каракларының күмәк җыры белән башлана. Халыкта популяр булган ашкынулы җыр һәркемнең күңелендә ат белән бәйле сәхифәләрне яңарта, тамашачыны ат караклары мохитенә алып керә. Тамаша дәвамында күмәк җырлар күп булып, аларның сайланышы һәм яңгырашы М.Яхъяевнең бу эшне белеп һәм яратып башкаруы турында сөйли. Әлеге ир-егетләр белән П.Майорова куйган биюләр, күмәк хәрәкәтләр дә күңелдә каләгатьлек хисе калдыра. Мөһиме: сәнгати югарылыкта башкарылган әлеге җырлар һәм биюләр спектакльне бизи, милли төсмерләр өсти, ат каракларының бердәмлеген, ашкынулы һәм куркыныч эш-гамәлләрен тоярга ярдәм итә. Сәхнә бизәлеше беренче карашка сәер булып тоела – әйләнә-тирәне тутырып машина тәгәрмәчләре аунап ята. Урыны белән алар утыргыч хезмәтен башкарса, шулай ук җиңел генә өстәл агыйна әйләнә. Ә инде урланган атны да тәгәрмәчләр белән күмеп куйгач, бары да ачыклана – режиссер вакыйгаларны бүгенгебез белән бәйләп кабул итүгә ишарә ясый икән. Бүген инде атны техника алыштырган кебек, элек ат урласалар, бүгенгебездә машина урлаучылар азмыни...

Вакыйгалар ат карагы Сибгатнең улы Фәйзел күзаллавында, аның уйлары, бәяләре белән кушылып бирелә. Бу үз чиратында әлеге хәлләрнең чынбарлыкта булуына да ишарә итә. Ат урлаучылар Сибгат кул астында ныклы төркемгә берләшкән. Алар арасында хезмәт бүленеше булган кебек, һәрберсе үз характеры белән аерылып тора. Берләре урланасы атны шикәр ашатып, икенчеләре кишер биреп тынычландыра. Ә инде ат сыртына менгән герой күзгә күренеп үзгәрә – җан ашкынуы кул һәм аяк хәрәкәтләренә күчеп, ул җил белән ярышка чыга. Г.Хөсәенова һәм Р.Сабитов башкаруындагы гаҗәеп темпераментлы музыка ярдәмендә бу халәт тамашачыга да күчә.

Вакыйгалар үзәгендә атаклы ат карагы – Сибгат. Э.Латыйпов әлеге геройны тыныч, сабыр, ихтыяр көченә ия, үз сүзеннән кире кайтмый һәм берәүгә дә баш бирми торган кеше итеп ача. Үзенең кешеләренә «бәбкәчләрем» дип эндәшсә, тегеләре «дәү эти» дип олылый. Аның бабасы, атасы да ат урлау белән шөгыльләнгән, Сибгат өчен дә ул яшәү максатына әйләнгән. Т.Миңнуллин фикерен дәвам итеп, режиссер бу кешенең эш-гамәлендә ачылган берничә принцибын аерып чыгара. Сибгат, патша властен танымаган кебек, совет властен да кабул итми. Ата-бабасын мохтаҗлык бу эшкә этәргән дип саный ул. Үзе дә авыр тормыштан, ачлыктан интеккәннәрне яныңа җыйган. Э.Латыйпов герое үзен кимсетелгәннәрне яклаучы итеп күрсәтә. «Мин мескеннәрне рәнҗетмим, мин рәнҗетүчеләрнең җаннарына тиям», ди ул. Вакыйгалар барышында ике улын сугышта югалткан, оныклары ачтан тилмергән Кариле крестьяны Нургалинең (Р.Әхмәдиев) атын урлаган Сәйхунга (Д.Хөснетдинов) каты җәза бирә һәм читкә куа. Шул ук вакытта Байкичү авылы старостасы Әхмәтҗан (А.Габдуллин) урланган атын сорап килгәч, аны куып чыгара. Алай гына да түгел, икенче атын урлауны да оештыра. Сибгатнең ярлы халыкка зыян китермәве кат-кат искәртелә. Аларның байлардан шулай үч алуын ярлы халык та яклый. Һәрхәлдә жандармнарга әләкләмичә гомер итүләре шуның белән бәйле. Әмма Сибгат корган әлеге яшәү рәвеше беренче күренешләрдә үк чатный башлый. Ул сөргендә вакытта кызы авыл мөгаллименә кияүгә чыккан, улы Фәйзел дә атасы юлыннан китмәячәген өзеп әйтә. Заманга нисбәтле мөнәсәбәтләрнең үзгәрешен Сибгат үзе дә тоемлый, әмма кабул итә алмый. Аның әледән-әле Гыйльметдиннән әкиятләр сөйләтүе, хәтерен яңартуы, алдагы чорлардагы ат урлауларын сагынып яшәве булып аңлашыла.

Сибгатнең әйләнә-тирәсендәге геройлар да чорның үзенчәлекле типлары булып ачыла: Ишми (Р.Таһиров,), кечкенә Фәйзел (Р.Хәертдинов), Григорий (Р.Йосыпов), Егор (Н.Газиев), Хафиз (А.Мифтахов), Гыйльметдин (Ф.Сафиуллин), Хәйрүш (А.Фазлыев), Шаһи (А.Шаһимәрданов), Каюм (И.Хәертдинов), Листунов (Р.Әхмәдиев). Д.Хөснетдинов уйнаган Сәйхун – усал, көнчел, үз мәнфәгатен кайгыртучы. Сибгат урынына башлык булырга теләгән бу бәндә башкалардан качып ат урлавы белән үк үзенең түбәнлеген күрсәтә. Төп геройның улы Фәйзел – үзгәрешләрне ачык тоемлаучы, үз язмышын хәл итәргә омтылучы егет. Э.Нургалиев аны тыныч, сабыр, кирәк урында үз сүзен әйтә ала торган егет итеп уйный. Атасы ат урларга мәҗбүр итсә дә, Фәйзел укырга, белем алырга омтыла. «Мин үземнән куркуларын теләмим. Хөрмәт итсеннәр» диюе белән атасы юлын, аның яшәү рәвешен кире кагуын ачык аңлата.

Совет властенең крестьяннарга җир бирүе, ирекле тормыш вәгъдә итүе Сибгат төркемен какшата. Хафиз, Егор кебекләр җиргә тартыла. Башкалары урларлык ат малы калмагач, кооперативларны таларга керешә. Сибгат тә элеккечә яши алмаячагын аңлый, әмма үзе әйткәнчә, «буйсынырга өйрәнмәгән җанын» үзгәртә алмый. Төп вакыйга улы Фәйзелнең, кайчандыр әшнәсе булган, хәзер качып йөрүче Сәйхун тарафыннан үтерелүе һәм Сибгатнең ачы язмышы алдында тезләнеп баш июе белән тәмамлана.

Т.Миңнуллин пьесасында Октябрь инкыйлабы яңа тормышка, бәхетле киләчәккә юл ача дигән фикер алга чыга. Режиссер А.Җаббаров исә 1917 елгы вакыйгаларны түнтәрелеш буларак бәяли. Гражданнар сугышы күренешләренә шактый урын бирелә, символлар, детальләр аша аның халыкка афәт, үлем, җимерелү алып килүе, андый хәлләр кабатланырга тиеш түгеллеге ассызыклана. Авылдашларның, хәтта туганнарның бер-берсен үтерү күренешләренең утлар ярдәмендә театр стеналарына төшерелүе, хореография элементлары, уңышлы сайланган музыка көчле тәэсир итеп, тамашачыны сискәндереп җибәрә. Совет власте гади халык көткәнне бирми. Инкыйлабтан соң властька килгән Мөгаллим дә үзгәрә. Р.Мөхәммәтҗанов герое, моңа кадәр халык мәнфәгатен кайгыртучы буларак ачылса, хәзер инде ул үзе теләгәнне власть исеменнән тартып алучыга әйләнә.

Матбугатта ат караучының «Ой мороз, мороз»ны җырлау күренеше бәхәс уяткан иде. Режиссер, күрәсең, төрле җирләрдә булып, шактый шомарган ат карагының телләр, шул исәптән җырлар белүе гадәти хәл дип саный. Шулай да әлеге күренеш ниндидер яңалык алып килми, аны төшереп калдырганнан спектакльгә зыян юк. Яңа хакимият вәкиле Мөгаллимнең власть исеменнән кешеләр кулындагы сәгатьләрне тартып алуы һәм беләгенә 5-6 сәгать тагып йөрү күренеше турында да уйланасы бар. Дөрес, аны хакимиятнең кешеләрне җәберләвенә, аерым вәкилләренең урланган әйберләрне үзләштерүенә метафора булып килә дип аңлатырга була. Яисә арттыру алымы ярдәмендә фаш итә дип тә әйтергә мөмкин. Әмма инкыйлабларга кадәр үк ат каракларына каршы чыга алган, Сибгат җибәргән икмәктән баш тарткан, хатынын һәм Фәйзелне ат карагы йогынтысыннан тартып алган, хәзер дә яшь егетнең укуы турында кайгыртып йөргән Мөгаллимнең шулай тиз генә байлыкка кызыгуы, халыкныкын үзләштерүе вакыйгалар барышыннан үсеп чыкмый. Хәер, режиссер һәм ярдәмчеләре керткән аерым үзгәрешләрнең, өстәмәләрнең төрлечә аңлануы һәм бәяләнүе табигый күренеш. Спектакльнең төрле уй-фикерләр тудыруы, бәхәскә этәрүе үзе үк аның актуальлеге турында сөйли.

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ.

256 ел яшәгән

Фантастикамы, әллә ялганмы? Кытайда Ли Циньюнь 256 ел яшәгән, диләр. Бу галимнәр һәм журналистлар бик яхшылап өйрәнгән факт санала. 1930 елда The New York Times газетасында басылган мәкаләдә Ченгду университеты профессоры Ву Чунг-цзенның 1827 елгы Кытай империясе хөкүмәте язмаларында Ли Циньюньне 150 яшь, 1877 елгы документларда исә 200 яшь тулу белән котлауларны табуы сурәтләнә. 1928 елда шул ук газета журналисты картның өлкән яшьтәге күршеләренең хатирәләре белән уртаклаша – алар үз бабаларының бала чакта ук Лины белүләрен, тик аның ул чакта ук инде өлкән яшьтәге ир булуы турында сөйли. Ли Циньюнь дару үләннәре белән сәүдә итә, ул аларны таулардан 10 яшеннән бирле җыйган һәм кайберләренең гомерне озайтуын ачыклаган. 40 ел буе годжи җиләге, линчжи, кыргый женьшень кебек үләннәр генә ашап һәм дөге шәрабы эчеп торган. 1749 елда, 71 яшендә, сугышу осталыгы мөгаллиме сыйфатында Кытай армиясенә кушылган. Лины бөтен кеше бик яраткан, ул 23 тапкыр өйләнгән, 200 тапкыр әти булган. Бала чагыннан ук укый-яза белгән, үләннәр җыя-җыя, 10 яшенә инде Ганьсу, Шанси, Тибет, Аннам, Сиам һәм Маньчжуриядә булырга өлгергән. Беренче йөз елын яшәгәндә, ул дару үләннәрен үзе җыйган һәм үзе саткан. Аннары башкалар җыйган үләннәрне сата башлаган. Гомере буе цигун сулыш күнегүләрен ясаган. Үлем түшәгендә ятканда, Ли үзенең атаклы гыйбарәсен әйткән: "Мин бу дөньяда эшләргә тиеш бөтен нәрсәне эшләп бетердем. Хәзер өемә кайтып китәм", – дигән. Бервакыт аннан озак яшәү серен сораганнар. Ли Циньюнь: "Йөрәгегез тыныч булсын, ташбака кебек утырыгыз, күгәрчен кебек дәртле йөрегез һәм сакчы эт кебек йоклагыз", – дигән. Ли үзенең озын гомерле булуының сере сулыш күнегүләрендә, эчке гармониядә һәм җан тынычлыгында, дип санаган. Диетаның да мөһим роль уйнаганы бәхәссез. Әмма шунысы гаҗәп: Җирдәге иң озын гомерле кеше моның сере нәкъ менә үзенең акыл халәтенә бәйле булуын яхшы белгән.

("The South China Morning Post").

Инкубатор балалары

Фаразлаулар буенча, якын арада эктогенез технологияләре киң кулланыла башлаячак, ягъни балалар махсус ясалма аналыкта үстереләчәк. Барысы да 2001 елда махсус үстерелгән тукымалардан шундый аналык булдырудан башланган. Аннары технологияне тычканнарда сынап караганнар, кимерүчеләрнең берничә эмбрионы шундый ясалма карында үстерелгән. Хәзер исә кеше белән сынау үткәрәсе генә калган. Кайбер галимнәр әлеге технологияне файдалы, дип саный, чөнки яралгы даими күзәтелеп торачак һәм баланың үле туу ихтималы булмаячак. Кайберәүләр исә эктогенезисны бөтенләй кулланмаска үгетли, чөнки ана белән бала арасындагы бәйләнеш югалуның яхшыга китермәвен аңлый. Ясалма аналык махсус кислород һәм кирәкле туклыклы матдәләр белән тәэмин итү системасын таләп итә. Эмбрионны яңа "машина-плацента"га тоташтырачаклар, тапшыргычлар аның үсешен даими күзәтәчәк. Мондый технологияне үзләре бала табарга сәләтсез булган аналар өчен куллану ихтималы тикшерелә, ягъни ул суррогат ананы алыштырачак. Танылган футурист Золтан Иштван яңа технология күп дигәндә 20 елдан файдалануга әзер булачак, тагын бер 30 елдан кулланыла башлаячак, дип саный. Аның фикеренчә, фән тарафыннан техник база инде бүген үк әзер диярлек, әмма этикага кагылышлы һәм юридик проблемалар хәл ителмәгән әле. Россия галимнәре исә этногенезис кулланыла башлаганчы тагын бер 50 ел үтәр әле, дип уйлый.

("Science").

Әспеле ботка, гөмбәле каһвә...

